МӘХӘЛЛӘДӘ



**Бәлешкә муллалар бәя бирә**

11 бит

СӘФӘРДӘН СОҢ



**Алман илендәге мөселманнар тормышы**

12 бит

ХӘЛӘЛ



**Чын хәләлгә акча жәл түгел**

13 бит



6+

# ДИН вә Мәгыйшәт

*Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! (Коръән, 3:103)*

*Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллануудан сакланыгыз!*

№ 8 (241). АВГУСТ – 2015 / ШӘҮВӘЛ-ЗӨЛКАГДӘ – 1436

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ









# ХАЖИЛАРЫБЫЗ СӘФӘРГӘ ӘЗЕР

**Рәхәт бер дулкынлану белән 8 сентябрь җитүен көтәбез. Бу көнне Татарстан хаҗиларының беренче төркеме Согуд Гарәбстанына хаҗ сәфәренә кузгала.**

Безнең "ДУМ РТ Хадж" программасының максаты халыкның төрле катлаулары өчен кулай бәядән хаҗ кылуны оештырудан гыйбарәт. Программа РФ Хөкүмәте каршындагы Хаҗ буенча совет стандартларына туры килә һәм ышанычлылыгы белән аерылып тора. Бәяләргә килгәндә, анысы сайланган программадан тора. "Стандарт" программасы 3600 доллар, "Эконом" программасы 3200 доллар, "Тизләтелгән" программа 4300 долларны тәшкил итә.

Хаҗга әзерлек быел да системага салынган тәртип белән барды. Әмма һәр хаҗ сезоны башкаларыннан үзенчәлекле булып чыга. Быел, мәсәлән, күпсанлы тәкъдимнәрне күздә тотып, хаҗилар комплектын яңарттык. Бу комплектта багаж букчасы, алдагы еллардан аермалы буларак, зур һәм тәгәрмәчле. Әлеге яңалык хаҗиларыбызга, бигрәк тә олырак яшьтәгеләргә, багаж күчерү һәм күтәрү мәшәкатьләрен җиңеләйтер дип өметләнәбез. Хаҗиларга ике төрле букча бирелә. Зур – юл букчасы һәм кечкенә букча. Шулай ук, комплектка китаплар да кертелде.

Тагын бер үзенчәлек: быел төркем җитәкчеләрен сайлаганда бик зур таләпләр куелды. Алар 3 тел белергә (татарча, русча һәм гарәпчә); стажлы, ягъни хаҗга барып кайткан һәм уңай бәяләмәгә ия булырга тиешләр.

Кеше бу сәфәргә бик нык әзерләнергә тиеш. Хажга, күп очракта, олырак яшьтәгеләр бара. Аларга үз сәламәтлекләрен ныгытырга, участок табиблары белән зур сәфәргә чыгу мөмкинлеге турында киңәшләшергә кушылды.

Хаҗ кылырга җыенган кеше үзен рухи яктан да әзерләргә тиеш. Биш вакыт намаз, Коръән уку, зикер кылу, салаватлар әйтү – Аллаһыга табынуның асылы әнә шулар, шушы гыйбадәтләрне җиренә җиткереп үтәү тиешле.

Хаҗ кылу тартипләрен өйрәнү – бик мөһим этап. Китаплар укып, догаларын өйрәнсәң, хаҗ кылырга җиңелрәк була. Без шулай ук Казанның Әниләр мәчетендә хаҗ кылу тәртипләрен өйрәтү дәресләре уздырдык. Ул дәресләрдә "ДУМ РТ Хадж"ның медицина хезмәте җитәкчесе, хаҗилар төркемнәре җитәкчеләре чыгыш ясады. Алар хаҗ турында һәм Согуд Гарәбстанында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, хаҗга медицина ягыннан әзерлек, хаҗда үз сәламәтлегеңне саклау ысуллары, ихрам халәте турында сөйләделәр.

"ДУМ РТ Хадж" төркеме хаҗиларга уңайлы шартлар тудыру ягын даими кайгыртып тора. Хаҗиларның яшәү урыннары сайлаган программаларга бәйле. Кунакханәләрнең Хәрам мәчетенә мөмкин кадәр якын булганын карадык. Хаҗиларыбыз өчен чиста, уңайлы, жайлы кунакханәләр әзерләнде.

Татарстан Республикасы хөкүмәтенә, Сәламәтлек саклау министрлыгына зур рәхмәтебезне белдерәсебез килә. Һәр ел саен алар безнең хаҗиларыбызны кайгыртып, шактый медикаментлар бүлеп бирәләр һәм аларны сәфәргә озата бару өчен тәҗрибәле медицина хезмәткәрләре белән тәэмин итәләр.

Хаҗ гыйбадәтләрен җиренә җиткереп үтәп, хажиларыбызның беренче төркеме 1 октябрь көнне туган ягыбызга исәнимин әйләнеп кайтырлар, дип көтәбез.

**Ранис ВАХИТОВ,**
**"ДУМ РТ Хадж" төркеме җитәкчесе**

# Чистайда Чистави мирасын барладылар

**Чистай шәһәрендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте игълан иткән Татар дин галимнәре елы кысаларында “Татар халкында суфичылык-ишанчылык традицияләре: Мөхәммәд Закир Камалов Әл-Чистави мирасы” дигән темага “Чистави укулары” узды. Фәнни-гамәли конференциягә Татарстан, Дагыстан, Башкортстан Республикаларыннан, Ханты-Мансийск, Мәскәү, Казан, Чистай, Санкт-Петербург шәһәрләреннән күренекле татар дин әһелләре, галимнәр, танылган татар дин белгечләренең туганнары, мәхәллә халкы жыелды.**



Әнәс мәчетендә үткәрелгән чарада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев, мөфти урынбасарлары Рәфыйк хәзрәт Мөхәммәтшин, Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, нәзарәтнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров, Чистай имам-мөхтәсибе Алмаз хәзрәт Шәрифуллин, Дагыстаннан килгән кунаклар – Дагыстан мөфтие урынбасары Әхмәд хаҗи Мөхәммәдов, республика башлыгы ярдәмчесе Мөхәммәд Мөхәммәдов, Ислам университетының тарих бүлеге җитәкчесе Морадулла хәзрәт Дадаев, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, Әнәс мәчетен төзетүче, чараның иганәчесе Тәлгать Әхмәтҗанов, мәчетнең имам-хатыйбы Әбүбәкер хәзрәт Газизов һәм башкалар катнашты. Моннан тыш Наил Таиров, Илдус Әмирханов, Алсу Хасавнех, Әлмира Таһирҗанова кебек күренекле тарихчылар, фән эшлекләре дә килгән иде.

Коръән аятьләрен укудан башланып киткән дини-фәнни чара рухи мирасны барлауга, динебез кыйммәтләрен аңлатуга, татар дин галимнәре эшчәнлеген өйрәнүгә багышланган чыгышлар, вәгазьләр белән дәвам итте. Конференция Чистай мөхтәсибәте тарафыннан әзерләнгән Чиставига багышланган видеосюжетны карау, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин мөхәррирлегендә дөнья күргән “III Чистави укулары җыентыгы”н, Чиставиның “Хозур” нәшрият йорты 3 телдә нәшер иткән “Мөршидләрнең фикерләүләре” китабын тәкъдим итү белән үрелеп барды.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин “Чистави укулары”н оештыручыларга, матди ярдәм күрсәтүчеләргә һәм шулай ук Чистави китапларын саклаган, аның рухи мирасын өйрәнгән Дагыстан дин әһелләренә рәхмәтен белдерде. “Безнең татар халкы исламдагы өч өйрәтүдән - гыйлемнән читкә китмәгән. Беренчесе аның хәнәфи мәзһәбе, икенчесе - матуриди гакыйдәсе, өченчесе - нәкышбәндия тарикате. Бабаларыбызның рухи мирасы да шул хакта. Чистави китабының ике басма варианты булуы мәгълүм. Аның берсе 1890 елда татар дин галиме Галимҗан Баруди тарафыннан нәшер ителгән. Икенчесе – шәех әл-Багини варианты. Дагыстан мөфтие урынбасары менә шул гарәпчә вариантны безгә бүләк итте һәм аны бүгенге чарага бастырып алып килдек”, – диде мөфти хәзрәтләре.

Баш казый Җәлил хәзрәт үзенең вәгазендә остазлар кадерен белергә чакырды. “Элек Мәрҗани мәчетенә Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин вәгазен тыңлар өчен бер сәгать алдан киләләр иде. Халык арасыннан үтеп керергә урын калдыралар иде, шундый бер хөрмәт белән тыңлыйлар иде. Кызганыч, хәзер яшьләр эксклюзив вәгазь эзләү артыннан гына йөриләр, остаз гыйлемен, догасын ишетим дип уйламыйлар ”, - диде ул.

Тарих фәннәре кандидаты Әскарь Гатин 60-70 елларда совет чорында динебез кыйммәтләрен җиткергән татар имамнарының аудиоязмаларын саклау, эзләү, табу, барлау хезмәтләренә игътибар юнәлтте. Аудиоязмаларны җыйнау һәм өйрәнү мәсьәләсен күтәрде.

Моннан тыш күп кенә чыгышлар Мөхәммәд Закир ишанның тормыш юлына, дини эшчәнлегенә багышланды. Мөхәммәд Закир Казан губернасының Чистай шәһәре мәчетендә ярты гасырга якын имам-хатыйб вазыйфасын үтәгән. Ул шунда “Камалия” мәдрәсәсен тәэмин иткән. Россиянең төрле өлкәләреннән һәм губерналарыннан ислам дине гыйлемен алырга килгән йөзләрчә яшьләргә тормышка юлны күрсәткән. XIX гасырның сиксәненче еллары ахырында “Камалия”дә якынча 400 шәкерт белем алган. Алар укырга Чистай өязеннән генә түгел, Казан, Уфа, Самара һ. б. губерналардан да килгәннәр. Р.Фәхреддин, Ф.Кәрими, Г.Гафуров-Чыгтай, Х.Фәйзи-Чистапули кебек мәшһүр шәхесләр әлеге мәдрәсәдә белем алганнар. 1882 елда шәех үз акчасына тагын бер мәчет салдыра. Шулай итеп, ул халкыбыз күңеленә мәгърифәтче, галим буларак кына түгел, юмарт мөселман булып та кереп калган.

Мөхәммәд Закир Чистави илнең үзәк өлешендә нәкышбәндия тарикатенең мөршиде була, ә икенче хөрмәтле ишан Зәйнулла Рәсүлев Россия империясенең көньяк-көнчыгышында ишан булып тора. Нәкышбәндия тарикате мөселман дөньясында киң таралган. Аның нигезендә дин әһелләре мөридләрен Коръән һәм сөннәттә язылганны үтәргә өнди.


***

**“Чистави укулары”** кысаларында дин әһелләре, галимнәр, мәхәллә халкы татар шәехе Мөхәммәд Закир Камалов Әл-Чиставиның каберенә зиярәт кылдылар, аның рухына багышлап догалар укыдылар. Олуг остаз (1804–1893) Чистайның беренче татар мөселман зиратында җирләнгән.

## Чиставиның “Мөршидләрнең фикерләүләре” китабы нәшер ителде

“Хозур” нәшрият йорты Мөхәммәд Закир әл-Чиставиның “Мөршидләрнең фикерләүләре (Тәбсыратул-муршидин)” дип аталган хезмәтен татар, рус, гарәп телләрендә нәшер итеп, “Чистави укулары”нда катнашучыларга таратты. Китап Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның татар шәехе Мөхәммәд Закир Әл-Чиставиның “Тәбсыратул-муршидин” хезмәте турында язган кереш сүзе белән ачыла.

Танылган татар шәехе Мөхәммәд Закир Әл-Чистави-Камаловның гарәп телендәге хезмәте хәзерге вакытта ике вариантта билгеле. Аның берсе – 1890 елда татар дин галиме Галимҗан Баруди тарафыннан Казан университеты типографиясендә нәшер ителгән. Икенчесе – дагыстанлы нәкышбәндия тарикате шәехе Шөгаеб әл-Багининың кулъязма мәҗмугасы арасында теркәлгән һәм тулысынча “Тәбсыратул-муршидин минәлмәшәихил-Халидийин” (Халидия мәшәехләреннән мөршидләрнең фикерләүләре) дип атала. Аның күчерелү вакыты итеп һиҗри исәп белән 1321, ягъни милади 1903-1904 еллар күрсәтелгән. Бу нөсхәдә Мө-




хәммәд Закир әл-Чиставиның кыскача тәрҗемәи хәле турында мәгълүмат белән бергә нәкышбәндия этикасы һәм ритуал гамәлләре мәсьәләсе турында тәфсилле аңлатмалар китерелә. Хезмәтне күчерүче Шөгаеб әл-Багини язганча, “төрле чыганакларда чәчелеп яткан бу 4 Халидия мәшәехләреннән мөршидләрнең фикерләүләре бибәһа кыйммәткә ия мәгълүматны автор җыйнап үзенең хезмәтенә туплаган”.

Хезмәттә нәкышбәндия тарикате этикасына зур урын бирелә. Мәсәлән, мөридләргә үгет-нәсихәт биреп, автор болай яза: “Ялганлама, үзеңне башкалардан югары куйма; Аллаһыга җисмани һәм рухи хезмәт итүдә барлык тырышлыгыңны куй, ләкин бу вакытта бернәрсә дә эшләмәдем дип исәплә. Үзеңнең ниятләреңдә эчкерсез бул, чөнки ният – хезмәт итүнең рухы”.

**Айзирәк ГӘРӘЕВА,**
**dumrt.ru**

# Корбан бәйрәме җитә



**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Казыйлар һәм Голәмалар шурасы җыелышында сүз Корбан бәйрәменә әзерлек турында барды. Быел Корбан бәйрәме 24 сентябрьгә туры килә. Җыелышта катнашучылар корбан нисабы күләме буенча бер фикергә килделәр, ул – 17 мең сум. Гаиләдә артык 17 мең сум акча булганда, корбан чалу ваҗиб, мәҗбүри санала.**

Шулай ук бәйрәм намазын уку вакыты расланды. Татарстанның барлык мәчетләрендә бәйрәм намазы кояш чыгып ярты сәгать узгач укыла. 24 сентябрьдә Казанда кояш 5 сәгать 31 минутта чыга, бәйрәм намазы сәгать 6.00 дә башлана.

Корбан чалулар бәйрәм намазыннан соң махсус урыннарда башкарыла, 3 көн дәвам итә.

# Корбан порталы ачылды

***Исламда корбан чалу йоласының тарихы, Ибраһим галәйһиссәлам белән аның улы Исмәгыйль галәйһиссәлам яшәгән чорга барып тоташа. Алар тормышындагы мөһим бер вакыйга ислам динендә Раббыбыз ризалыгы өчен корбан чалу йоласына нигез сала. "Кәүсәр" сүрәсенең 2 нче аятендә Аллаһы Тәгалә: "Раббың ризалыгы өчен намаз укы һәм ятимнәрне вә фәкыйрьләрне ашатыр өчен корбан чал!" – дип әмер бирә. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисендә дә: "Корбан чалыгыз, бу – атабыз Ибраһим галәйһиссәламнең сөннәте", – диелә.***

Әмма корбан чалучы шуны аңларга тиеш: Аллаһы Тәгаләгә корбанның каны да, ите дә кирәкми, Аңа безнең тәкъвалыгыбыз гына ирешә. Бу хакта Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай ди: "Аларның (корбанга чалынган хайваннарның) ни ите, ни каны Аллаһыга түгел, Аңа фәкать сезнең тәкъвалыгыгыз гына ирешә. Сезне тугры юлга бастыручы Аллаһының бөеклеген танырсыз (Аңа тәкбир әйтегез), дип бу хайваннарны шулай итеп сезнең файдагызга бирдек. (Ий Мөхәммәд), игелек кылганнарны




сөендер" ("Хаҗ" сүрәсе, 37 нче аять).

Аллаһыны чын күңелдән сөйгән, матди мөмкинлеге булган тәкъва кеше Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен корбан чалып, гаиләсен, туганнарын, килгән кунакларын, күршеләрен, фәкыйрьләрне һәм мескеннәрне сыйлый. Әмма еш кына корбан чалырга ниятләгән кешедә, корбанлык терлекне каян алырга, дигән сорау туа. Корбанлыкка теләсә нинди хайван ярамый бит әле, ул сәламәт һәм яхшы ашатылган булырга тиеш. Бер яки ике күзе дә сукыр, тешләре коелып беткән, колаксыз, мөгезе сынган, койрыгы өзелгән терлек тә корбанлыкка ярамый. Корбанлык терлек белән сату итүчеләр турында мәгълүмат аз булу аркасында кайчакта шулай да килеп чыга: корбан чалучы ышанычлы сатучыны табуын тапкан, әмма тегесенең инде терлеге бетеп киткән. Нәтиҗәдә башка кешедән кыйммәтрәк бәягә сатып алырга туры килә. Бу аңлашыла да: көне-сәгате җиткәндә бәяләр шактый күтәрелә. Сатып алучының кесәсен кайгыртучы фермерлар да бардыр анысы, әмма корбан чалучы белән корбанлык хайван сатучыга бер-берсен табарга кыенрак.

Менә шуны күздә тотып, Корбан бәйрәме якынлашып килгәндә Islam-today корбанлык терлек белән сәүдә итүчеләр һәм сатып алучылар өчен махсус портал ачты (**http://kurban.m7-ya.ru**). "Корбан-портал" ике як өчен дә кулай сәүдә мөнәсәбәтләре булдыруны күздә тота: сайтта корбанлык терлек сатучы үз тәкъдимнәрен урнаштыра, ә сатып алучы исә корбанга заказ биреп, аны тиз һәм уңайлы юл белән сатып ала.

Корбан бәйрәменә корбанлык терлек сатучылар һәм фермерлар инде бүгеннән үк "Корбан-портал"да теркәлә ала. Моның өчен түбәндәге ссылка буенча кереп, махсус форманы тутырырга кирәк:

# Мөфти чит илләрдә укучы яшьләр белән очрашты

**Чит илләрдәге дини уку йортларында белем алучы яшь мөселманнар Казанның "Тынычлык" мәчетендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин белән очраштылар.**

Әлеге чарада шулай ук мөфти урынбасары, Россия ислам институты ректоры, профессор Рәфыйк Мөхәммәтшин, нәзарәтнең мәгариф бүлеге җитәкчесе Айдар Карибуллин, "ДУМ РТ Хадж" программасы җитәкчесе Ранис хәзрәт Вахитов, Марокко галиме Габдрәхим Ләкрим катнашты.


Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин яшьләргә республиканың дини мәгариф өлкәсендәге яңалыклар турында сөйләде. Традицион ислам кыйммәтләрен торгызырга һәм гыйлемнәрен кирәкле, халык өчен файдалы юнәлештә кулланырга чакырды. Камил хәзрәт татар дини мирасын өйрәнү мөһимлегенә аеруча басым ясады. Татар дини мирасының ислам фәннәре буенча гыйлем чыганагы булуы хакында әйтте. Моннан тыш Камил хәзрәт яшьләрне Болгардагы Ак мәчеттә Коръән өйрәнергә чакырды. Бирегә Коръән өйрәнү буенча яртыеллык курслар октябрьдә башланыр дип көтелә.

Мөфти урынбасары Рәфыйк Мөхәммәтшин чит ил дини уку йортларында белем алган студентларның безнең җирлек мохитенә авыр ияләшүләре хакында сөйләде. Аның сүзләренә караганда, чит илләрдә укып кайтучылар үз туган җирләренең тарихын, ватандашларының дини тәгълиматын бик аз беләләр. Бу гыйлем дә булса, аларга туган җирләрендә үз урыннарын табу, эшкә урнашу күпкә җиңелрәк. Рәфыйк хәзрәт шулай ук бүгенге көндә республикада мөселманнар өчен бик күп мөмкинлекләр, шартлар тудырылуына һәм төпле, акыллы гыйлемгә ия дин әһелләренең һәрвакыт кирәк булачагына игътибар юнәлтте.

Очрашу барышында шәкертләр күп сандагы сорауларын бирделәр, фикерләре белән уртаклаштылар. Шулай ук аларны мөселманнар өчен эшләнгән "Ziyarat.ru" социаль челтәре белән таныштырдылар. Социаль челтәрне эшләгәндә исламның барлык таләпләре искә алынган. Алга таба аның исеме дә үзгәрергә мөмкин.

Очрашуның бер өлеше футбол кырында узды. Яшьләр "Динамо" стадионында мөфти белән бергә футбол уйнадылар.

# Әлки районы имам-мөхтәсибенә 85 яшь тулды



**Әлки районы имам-мөхтәсибе Исламетдин хәзрәт Шәйхетдинов үзенең 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Хәзрәтне туган көне белән котларга бу көнне район имамнары, аның шәкертләре, күрше район имам-мөхтәсибләре, дуслары, туганнары һәм хезмәттәшләре җыелды. Чарада шулай ук мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин һәм Әлки муниципаль районы башлыгы Александр Никошин катнашты.**

Бәйрәм Изге Коръән уку белән башланып китте һәм чакырылган кунакларның котлау сүзләре белән дәвам итте. Татарстан мөфтие, ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм үз исеменнән юбилярны Рөстәм хәзрәт Хәйруллин тәбрикләде һәм рәхмәт хаты, истәлекле бүләк тапшырды.

"Исламетдин хәзрәт районыбызның барлык милләт вәкилләрен берләштерүче шәхес. Кешеләр арасында дустанә мөнәсәбәт урнаштыруда, уртак тел табып, төрле аңлашылмаучанлыкларны хәл итүдә аңа тиңнәр юк. Аның белән аралашырга да, эшләргә дә җиңел", - дип билгеләде район башлыгы Александр Никошин.


Бу кичне Исламетдин хәзрәт турында күп кенә җылы сүзләр һәм күркәм теләкләр яңгырады. Бәхәссез, катнашучыларның һәркайсы аның эшчән һәм кешеләргә карата уңай мөнәсәбәтен билгеләде.

# Мәчетләр каршындагы курсларга лицензия кирәкми

**Россия Президенты "Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында"гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында"гы (13.07.2015 № 261) законга кул куйды. Законның 5 нче маддәсенә 5 нче пункт өстәлде. Әлеге пункт нигезендә мәчетләр каршындагы курсларда дингә өйрәтүгә һәм дини тәрбия бирүгә лицензия кирәкми.**

Яңа пункттан аңлашылганча, дини берлек, Россия законнары һәм дини оешманың эчке кагыйдәләре нигезендә, дингә өйрәтергә һәм дини тәрбия бирергә хокуклы. Дин өйрәнү һәм дини тәрбия белем бирү эшчәнлеге буларак саналмый. Шуңа күрә дә хәзер прокуратура һәм башка дәүләт органнары мәчетләр каршында оештырылган курсларда укуукыту эшчәнлеге алып бару өчен лицензия таләп итәргә тиеш түгел.

# Хаҗ



**Матди һәм физик мөмкинлекләре булган һәр мөселман гомерендә бер тапкыр зөлхиҗҗә аенда Мәккәгә хаҗга барырга тиеш. Мәккә – мөселманнарның Гарәп ярымутравында урнашкан изге шәһәрләреннән иң әһәмиятлесе.**

Хаҗ берничә төрле йоладан гыйбарәт: аңа ихрам (хаҗ киемнәрен) кию, Гарәфә көнендә Гарәфәт тавында тору, Кәгъбәтуллаһны җиде мәртәбә әйләнү, Сафа һәм Мәрва таулары арасында йөрү, таш ату, корбан чалу һәм башкалар керә. Хаҗ гамәлләре башкарыла торган һәр урын нинди дә булса тарихи вакыйга белән бәйле, хаҗ йоласының һәркайсының аерым мәгънәсе һәм тарихы бар.

Хаҗ вакытында планетаның барлык мөселманнары берләшә. Раса һәм милләтенә карамастан, барлык мөселманнар да бер үк гамәлләр һәм йолаларны башкара, барыбыз өчен дә Бер булган Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәттә булалар. Хаҗ гамәлләрен үтәгәндә барлык кешеләр дә – хуҗа һәм хезмәтче, хөкемдар һәм гади кеше бертигез дәрәҗәдә була. Бай һәм ярлы ир-ат мөселманнар бертөрле кием кия, ягъни ике кисәк ак тукымага төренәләр.

Хаҗ иманлы кешеләргә Кыямәт көнен искәртеп тора, ягъни бу көнне барлык кешеләр дә Аллаһы Тәгалә каршына ялангач килеп басып, дөньялыкта кылган гамәлләре өчен җавап тотачаклар. Кыямәт көнендә кешегә аның чыгышы да, гомере буена туплаган мал-мөлкәте дә, җәмгыятьтәге урыны да ярдәм итмәячәк.

Хаҗ кылу һәр мөселманның тормышында мөһим вакыйга, гөнаһларның ярлыкануына ирешү, тормышыңны яңадан күзаллау һәм яхшыга таба үзгәртү мөмкинлеге ул. Мөселманнарның күбесе хаҗ кылганнан соң башкача яши башлыйлар, элекке гөнаһларын ташлыйлар, ислам динен тирәнрәк аңлый һәм тоемлый, Аллаһы Тәгаләдән күбрәк курка башлыйлар, әү гомерләрен "хаҗга кадәр" һәм "хаҗдан соң"га бүлеп карыйлар.

**"Ислам турында сөйләшик" энциклопедиясеннән**

# Хаҗ кылу кайчан фарызга әйләнгән?


**Тирмизи һәм Ибн Маҗәһ: "Пәйгамбәр галәйһи вә сәлләм һиҗрәткә кадәр 3 тапкыр хаҗ кылды", - ди. Ибне Хәҗәр: "Бу – әнсарларның, хаҗ кылгач, Мина үзәнендәге Гакабәгә килүенең санына нигезләнә", - дип әйтә. Беренче тапкыр килгәч, алар Аллаһының Рәсүле саләллаһу галәйһи вә сәлләмгә икенче тапкыр килергә дип вәгъдә бирә, ә икенче кат килгәч, беренче тапкыр Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә бәйгать итә (антлы вәгъдә итә), ә өченче тапкыр килгәч, алар икенче тапкыр бәйгать бирә ("Фәтхел-Бәри" (8/74)).**

Галимнәр арасында: "Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм һиҗрәткә кадәр ел саен хаҗ кылган", - дигән фикер дә бар. Анысы ничек кенә булмасын, хаҗның һиҗрәтнең унынчы елында фарыз булуы турында галимнәр уртак бер фикердә. Ул аңа кадәр фарыз булмаган, Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм шул хаҗдан соң башка хаҗ кылмаган. Шуңа күрә дә күп сәхабәләр бу хаҗны хушлашу хаҗы, ислам хаҗы яки Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм хаҗы дип атап йөрткән. Бу вакыйга турында сөйләнгән хәдискә имам Мөслим хушлашу хаҗы дип исем биргән.

Бохари һәм Мөслим тапшырган, Габдел-Кайс кабиләсеннән килгән делегация турындагы хәдис хаҗның һиҗрәтнең унынчы елында фарыз булуы файдасына дәлил булып тора. Ул хәдистә болай диелә: "Габдел-Кайс кабиләсеннән килгән делегация Аллаһының Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнән: "Аны бездән соң калучыларга тапшыра алсын өчен һәм без җәннәткә керә алсын өчен ачык әмереңне безгә тапшырсаң иде", - дип сорадылар. Ул аларга: "Мин сезгә (исламның) дүрт (кагыйдәнамәсен) башкарырга әмер итәм һәм дүрт төрле (гамәлне) башкаруны тыям", - диде. Аннары ул аларны аңлатып китте: "Аллаһыга иман китерү! Бу – Аллаһтан башка илаһ юклыгына, Мөхәммәднең Аның Рәсүле булуына шаһәдәт китерү; намаз уку; зәкят бирү; рамазан аенда ураза тоту; хәрби ганимәтнең биштән берен бүлеп бирү". Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм шаһәдәт китерү шартын калган дүртесенә дә өстәмә итеп тапшырган булуы ихтимал. Чөнки шаһәдәт китерү шарты – барысына да билгеле. Һәм дә ул (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде), аның калган дүртесе өчен дә төп шарт булуын расларга һәм аңлатырга теләп бу шартларны тагын бер кабатлаган булса кирәк. Бу делегация һиҗрәтнең тугызынчы елында килгән.

**"Шура", №9**

# Түземлелек төрләре



**Арыдым... Түзәр хәлем калмады... Тормышым шулкадәр авыр, мәшәкатьле, кыенлык артыннан кыенлык... Зур, бөтерелеп аккан елганың агымына каршы йөзеп барган кебек тоям үземне! Сабырлыгым бетеп бара, инде нишләргә?**

Улы, тәмам төшенкелеккә бирелеп, шулай зарланып алгач, әти кеше дәшмичә аш бүлмәсенә чыгып китте. Бераздан ул зур бүлмәдә диванда боегып утырган улын үз янына чакырып алды:

- Улым, әйдә, чык әле монда!

Кухняга чыккач, егет газ плитәсендә суы кайнап торган өч кечкенә кәстрүлне күреп алды. Әтисе дәшминитми генә бер кәстрүлгә шактый зур кишер, икенчесенә йомырка салды, өченчесенә исә кәһвә сибеп җибәрде.

Чәй эчеп алганнан соң, әти кеше пешкән кишер белән йомырканы чыгарып тәлинкәгә салды, ә чынаякларга кәһвә койды. Аннан соң шуларга ишарәләп, сорап куйды:

- Бу ризыклар әүвәлге халәтләреннән ничек булса да үзгәрдеме?

- Кишер белән йомырка пеште, ә кәһвә кайнар суда эреп бетте, – дип иңбашларын сикереп алды егет.

- Юк, улым, бу тыштан караганда гына шулай,– диде әтисе. – Менә кара: кишер кайнап торган суга эләккәч, йомшарып бетте, ә юка гына кабыклы, кагылсаң ватылып сытылырга торган йомырка, киресенчә, катыланды. Капкайнар суга эләккәч, аларның һәрберсе үзенчә үзгәрде. Кешеләр дә нәкъ шулай – йомшак, зәгыйфь булганнар авырлык кичергән вакытта, сабыр итеп, аякта нык басып кала алса, тышкы яктан көчле булып күренүчеләр нигәдер каушап, коелып төшә.

- Ә кәһвә? – дип кызыксынып сорады улы.

- Ә монысы иң гыйбрәтлесе! Чит мохиткә эләккәч, ул тиз генә эреп бетте дә аны хуш исле эчемлеккә әйләндереп куйды. Кешеләр арасында да авыр, проблемалы хәлне өр-яңа, матур вәзгыятькә үзгәртеп, шуннан файда ала белүчеләр бар. Син дә, улым, шундыйлардан булырга тырыш һәм беркайчан да өметеңне өзеп төшенкелеккә бирелмә...

**Ришат КУРАМШИН**

## Хәзрәткә соравым бар

*"Миңа күптән түгел Апанай мәчетендә бер мәҗлестә катнашырга туры килде. Мәҗлес соңында җәмәгать белән намаз укыдык. Минем янәшәмә Казанның күркәм ике абыстае туры килгән икән. Шулар намаз укуымны күзәтеп торганнар да соңыннан кайбер җитешсезлекләремне әйттеләр. "Сул кул белән истинҗа кылалар, бала, зикер әйткәндә сул кул бармакларын бөгәргә ярамый", - диде берсе. Икенче абыстай исә аңа каршы төште: "Безгә фәлән хәзрәт ярый дип өйрәтте, әмма зикер әйткәндә уч төбен өскә каратасы түгел, киресенчә, аска таба каратып, бармак буыннарына басып-басып алырга кирәк". Мин ни әйтергә белми аптырап торган арада беренче абыстай, сәҗдәгә киткәндә терсәкләрне намазлыкка тидерергә ярамый, этләр генә шулай эшли, дип тә өстәде. Дөресе ничек була икән, хөрмәтле Нияз хәзрәт газета аша шуны аңлатып бирсә иде. Намаз вакытында хәрәкәтләрне дөрес ясамыйча гөнаһлы булсам, кеше игътибарын үземә җәлеп итеп, тагы бер гөнаһлы булырмын, дип бик куркам. Наилә С., Казан".*

**Сезнең сорауга Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе, Апанай мәчете имам-хатыйбы Нияз хәзрәт САБИРОВ җавап бирә:**

Хөрмәтле Наилә ханым! Сезгә Аллаһның чиксез сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын! Зикер әйткәндә уң кул бармакларын куллану хәерлерәк, ләкин сул кулныкын да бөгәргә ярый. Уч төбен аска да, өскә дә каратырга мөмкин. Аллаһы Тәгалә безгә динне җиңеләйтте һәм авырайтмаска кушты. Аллаһның Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: "Диндә артык җентеклелекне һәм таләпчәнлекне күрсәтүчеләр һәлак булырлар", – дигән (Ибн Маҗәһ, Насаи).

Хатыннар намазы ирләр намазыннан бераз аерыла. Сәҗдә вакытында ирләр корсакларын, ботларын һәм беләкләрен намазлыкка яки кабыргаларына тидермиләр, ләкин хатыннар, ирләрдән аермалы буларак, кысылыбрак сәҗдә кылалар. Бу хакта сөекле Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдисләрендә аңлатып калдырган: "Хатын-кыз сәҗдә кылганда, тәннең бер өлешен җиргә (намазлыкка) тидерсен, чөнки алар бу мәсьәләдә ирләр кебек түгел" (Әбү Давыд). "Хатын-кыз корсагын ботка кысыбрак сәҗдә кылсын" (Бәйһәкый). Шулай итеп, хатын-кыз сәҗдә вакытында терсәкләрен намазлыкка тидереп укырга тиеш. Ирләргә исә терсәкләрен намазлыкка тидерергә ярамый, чөнки хәдис-шәрифтә әйтелгән: "Урталыкны саклагыз, сәҗдә вакытында этләр кебек беләкләрегезне намазлыкка җәймәгез" (Бохари). "Сәҗдә кылганда җиргә уч төбен куегыз һәм терсәкләрегезне күтәрегез" (Мөслим).

Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга намазларыбызны вакытында һәм дөрес итеп ихластан укырга насыйп итсен!

# Кадерле хәдис

***Халид бин Вәлидтән риваять ителә: "Бервакыт Аллаһы Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) янына бер бәдәви (күчмә тормыш белән яшәгән гарәп) килгән дә шундый сорау биргән:***

- Йә Аллаһының Рәсүле, миңа бу дөньяда һәм ахирәттә нәрсә файда китерәчәк?

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһының рәхмәте вә сәламе булса иде) аңа:

- Син үзеңне борчыган әйберләрне әйт, - дигән.

Бәдәви:

- Мин гыйлемле кеше булырга телим, - дигән.

Пәйгамбәр (аңа Аллаһының рәхмәте вә сәламе булса иде) аңа:

- Тәкъва бул, шул вакытта гыйлемле дә булырсың, - дип җавап биргән.

- Мин бай кеше булырга телим.

- Аздан канәгать булырга өйрән, шул чакта иң бай кеше син булырсың.

- Мин гадел кеше булырга телим.

- Үзеңә ни телисең – башка кешеләргә дә шуны ук телә, шул вакытта иң гадел кеше син булырсың.

- Минем иң яхшы кеше буласым килә.

- Кешеләр өчен файдалы бул, шул вакытта син кешеләр арасында иң яхшысы булырсың.

- Минем Аллаһы каршында мәртәбәле буласым килә.

- Аллаһыны күбрәк зикер ит, шул вакытта Аның алдында дәрәҗәң артыр.

- Мин Аллаһыга китергән иманымның камилләшүен телим.

- Холкыңны яхшы якка үзгәрт, Аллаһыга китергән иманың камилләшер.

- Минем Аллаһыга тырышып хезмәт күрсәтүчеләр рәтендә буласым килә.

- Аллаһыга мөрәҗәгать иткән вакытта күрмәсәң дә Аны күргән кебек итеп мөрәҗәгать ит. Чынлыкта, Ул сине һәрвакыт күреп тора.

- Мин Аллаһының итагатьле коллары санында булырга телим.

- Аллаһының сиңа йөкләгән бурычларын төгәл үтә, шунда Аллаһының итагатьле коллары исемендә булырсың.

- Минем Кыямәт көнендә нур сирпеп кубарыласым килә.

- Үзеңне һәм башкаларны җәберләмә, шул чагында Кыямәт көнендә нур сирпеп кубарылырсың.

- Кыямәттә Раббыбызның рәхим-шәфкать күрсәтүен телим.

- Үзең башка кешеләргә рәхимле һәм шәфкатьле бул, шунда Раббың да Кыямәттә сиңа рәхим-шәфкатен күрсәтер.

- Мин гөнаһларымның азрак булуын телим.

- Һәрвакыт гөнаһларыңны кичерүен сора – гөнаһларың кимер (ягъни "Әстәгъфируллаһ" дип әйт).

- Минем ихтирамга лаек кеше буласым килә.

- Кешеләргә үз борчумәшәкатьләрең турында сөйләмә, ихтирамга ия булырсың.

- Минем иң көчле кеше буласым килә.

- Аллаһыга сыгын, шул чакта иң көчле кеше булырсың.

- Аллаһының минем җирдәге ризыгымны арттыруын телим.

- һәрвакыт чиста һәм пакь йөр, һәрвакыт тәһарәтле бул – Аллаһы синең җирдәге ризыгыңны арттырыр.

- Минем Аллаһы һәм Аның Рәсүленең сөеклеләре исемлегендә буласым килә.

- Аллаһы һәм Аның Рәсүле яраткан әйберләрне ярат, аларның сөеклеләре санында булырсың.

- Минем Кыямәттә Аллаһы дәһшәтеннән азат буласым килә.

- Бервакытта да Аллаһыга ачуың чыкмасын, шул вакытта Кыямәттә Аның дәһшәтеннән азат булырсың.

- Догаларымның Аллаһыга барып ирешүен телим.

- Хәрам кулланудан тыел, Аллаһы синең догаларыңны кабул итәр.

- Раббымның Кыямәттә мине башкалар алдында оятка калдырмавын теләр идем.

- Җенес әгъзаңны зинадан тый – Раббың Кыямәттә сине башкалар алдында оятка калдырмас.

- Кыямәттә Раббыбызның минем гөнаһларымны халыкка ирештермәвен теләр идем.

- Үз кардәшләреңнең җитешсезлекләрен сөйләп йөрмә – Кыямәттә Раббыбыз гөнаһларыңны халыкка ирештермәс.

- Гөнаһлардан (кырын гамәлләрдән) нәрсә аралый?

- Күз яшьләре, Аллаһыга итагать итү һәм авырулар.

- Яхшы гамәлләрнең кайсысы Аллаһы өчен өстенрәк?

- Күркәм холык, гадилек һәм авырлыклар килгәндә сабырлык күрсәтү.

- Яман гамәлләрнең кайсысы Аллаһы каршында иң күңел кайтара торганы?

- Яман холык, үз нәфесеңнең колы булу.

- Ахирәттәге тормышта Аллаһы дәһшәтен нәрсә җиңеләйтә ала?

- Яшерен бирелгән сәдака, туганлык җепләрен саклау.

- Кыямәттә тәмуг утын сүндерергә нәрсә сәләтле?

- Бу дөнья тормышында бәла-казалар килгән вакытта сабырлык күрсәтү.

**Әлеге хәдисне имам Әхмәд ибн Хәнбәл тапшырган. "Шура", № 9**

# Күз тимәсен өчен дога

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Хәсән белән Хөсәенгә (Аллаһ алардан риза булсын) күз тимәсен дип мондый дога кылган: **"Әгүүзү бикәлимәәт-илләһит-тәәәммәти миң күлли шәйтаанир үә һәәәммәти үә миң күлли гәйнил ләәәммәһ" (Һәр шайтаннан, зарарлы әйберләрдән һәм начар күзләрдән сүзләрнең хөрмәтенә Аллаһка сыенам;** Бохари 4: 119).

Күз тиюдән тагын бу аятьне уку киңәш ителә: **"Үә ий йәкәәд-үлләзиинә кәфәруу ләйүз-ликуунәкә биәбсаариһим ләммәә сәмигүззикра үә йәкуулүүнә иннәһүү ләмәҗнүүн. Үә мәә һүә илләә зикрул лиль-гәәләмиин". (Чынлап та, шул кяферләрнең, Коръәнне ишеткән вакытта, сине күзләре белән бәреп егасы килә иде. "Ул, һичшиксез, акылдан язган кеше", – дияләр. Ә бит Коръән бөтен галәмнәр өчен шәфкатьтән башка бер әйбер дә түгелдер"** ("Каләм", 51-52).

**("Авыр вакытларда укыла торган догалар", "Хозур")**



# Мөэминнәрнең сират күперендәге хәле

Аллаһы Тәгалә аяти-кәримәсендә мөэминнәрнең сиратны ничек кичәчәкләрен белдерә: **"Кыямәт көнендә мөэмин ирләрне, мөэминә хатыннарны күрерсең. Аларның алдыннан да, уң ягыннан да нурлары яктыртып барыр. Бүген сезгә сөенче! Чишмәләре агып торган җәннәт бакчаларына керерсез. Сез анда мәңге калырсыз. Бу – бөек котылышның үзе булыр"** ("Хәдид", 57:12).

"Әй, иман китергәннәр"! Ихлас тәүбә итеп, Аллаһка кайтыгыз, Ихтимал, сезнең хаталарыгызны Аллаһы кичерер. Пәйгамбәрне һәм аның белән бергә иман китергәннәрне хур итмәс. Сезне чишмәләре агып ята торган җәннәтләренә кертер. Аларның алдыннан, уң якларыннан нурлары яктыртып барыр. Алар әйтер: **"Әй, Раббыбыз! Тулы ит нурыбызны, гафу кыл барыбызны. Һәрнәрсәгә дә Синең кодрәтең җитү хактыр"** ("Тәхрим", 66:8).

Менә шулай, Аллаһы Тәгалә безгә мөэминнәрнең сираттагы хәлен аңлата, Ибне Маҗәһ риваять итүенчә һәм бу аяти-кәримәнең тәфсирендә (Ибне Кәсир) аңлатылганча, мөэминнәр үзләренең гамәлләренә күрә нурланачаклар. Кайберсенең нуры таулар кебек яки гәүдәсе кадәр. Кайберсенең биленә тикле, кайберәүләрнең аягы яки тырнагы кадәр булачак. Һәм хәтта иң соңгысына да җәһәннәм: "Әй, мөэмин тизрәк кич, синең нурың минем утымны сүндерә!" – дип тавыш бирәчәк.


Нурының таулар кадәр булуын һәм җәһәннәм өстеннән яшен кебек кичүне кемнәр генә теләмәс икән? Шул сәбәпле сиратны тизрәк кичәр өчен күбрәк изге гамәл кылырга ашыгыйк.


**("Мәңгелеккә юл тотучының ахирәт паспорты"ннан, "Хозур")**

#8 (241) август 2015/
шәүвәл – зөлкагдә – 1436

# Күркәм

**"Иман" нәшриятында совет чорында халыкны иманга, хакыйкатькә, әдәпәхлакка өндәгән, дин юлында армыйталмый хезмәт иткән, 1970-1990 елларда Мәрҗани мәчетенең имамы булып торган мөхтәрәм Әхмәдзәки хәзрәт САФИУЛЛИН хакында хатирәләр җыентыгы басылып чыкты. Әлеге китапта Әхмәдзәки хәзрәтнең үзенең дә берничә вәгазе урын алган. Шуларның берсен газета укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.**






Мөхтәрәм җәмәгать! Бу җомгада кыска гына итеп, әз генә вакытыгызны алып, күркәм холык, мөселманнарның холкы нинди булырга тиешлеге хакында берничә аять сөйләп китәргә булдым. Аллаһы Тәгалә барчагызга да тыңларга, вәгазьләнергә насыйп итсә иде.

Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгалә тарафыннан Коръән аятьләрендә мөэминнәргә менә шулай, менә болай эшләгез, йә булмаса, алай эшләмәгез, болай эшләмәгез диелсә, мөэминнәрнең сүзе бары тик "ишеттек, буйсындык" булырга тиеш, шулай әйтмәсә, "миңа Аллаһның сүзе кирәкми" дисә, ул кеше диннән чыккан була. Рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәллам үзе исән вакытында Мәдинәдә монафыйклар эчтән дошман, тыштан мөселман булып йөриләр иде. Рәсүлуллаһка аятьләр иңдерелә башлагач, алар көлеп: "Әйдәгез әле, безгә яраклы сүз булмас микән, Мөхәммәдкә каршы килергә бер җай табылмас микән", – диләр иде.

Беркөнне Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәллам янына керәләр, Аллаһы Тәгаләдән нинди сүз килгәнен тыңлыйлар. Билгеле ки, Аллаһы Тәгалә исламга тиң сүзләрне генә иңдерә, монафыйкларга файдалы сүз юк анда. Монафыйклар җәһәннәм утының иң аскы катында булырлар, дигән сүз бар. Шуннан соң монафыйклар бер-берсенә караша да, чыгыйк моннан, безгә яраклы сүз булмады, диләр. Менә шуның өчен Аллаһы Тәгалә аларның калебләрен исламнан түндерде. Бу ни өчен шулай соң? Чөнки алар Аллаһы Тәгаләнең Китабына разый түгел. Боларны вәгазь буларак сөйлим, мөхтәрәм җәмәгать. Вәгазьне бер кешегә генә төбәп сөйләмибез. Бөтенебезгә: сезгә дә, безгә дә Аллаһының сүзе бер. Аллаһы хозурында динебез пакь булсын дисәк, чын хакыйкый мөселман булсак, вәгазь нинди рәвештә сөйләнә икән, шуны гамәлгә ашыру – безнең мөкатдәс бурычыбыз.

Раббыбыз Аллаһ аларның калебләрен ислам диненнән түндерде. Ни сәбәптән? Чөнки алар Аллаһы Тәгаләнең аятьләрен аңларга теләмәделәр. Безнең вазыйфабыз – вәгазь сөйләү, шуны яхшы аңлагыз, бу – безнең мәдрәсәбез. Мәҗлестә бер кисәк вәгазь сөйлибез дә, мәчеткә килеп, хәзрәт сөйләгәнне игътибар белән тыңлыйбыз. Кыямәт көнендә йөзегез ак булсын дип, Аллаһы Тәгалә биргән гыйлемне беркадәр сезгә җиткерәбез, шуның өчен Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгалә безгә сөйләргә, сезгә тыңларга, күңелләребезгә иман нурын салып, Хисап көнендә бер-беребезгә хәерле шаһитлар булырга насыйп итсә иде. Безнең вазыйфабызны беркем дә тыя алмый, хәтта хакимиятебездә дә: "Коръән белән хәдистән башка нәрсә сөйләмәгез", - диләр, диннән ерак кешеләр булсалар да.

Ибн Хаттаб әйтте: "Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә вәхи килгән вакытта аның янында утырдык һәм без умарта кортыныкы сыман выжылдаган тавыш ишеттек. Шуннан соң ул берәр сәгать вакыт утыргач, кыйбла тарафына борылды, ике кулын күтәреп: "Йә, Раббым, безгә нурыңны, бәхетсәгадәтне арттырсана, киметмәсәнә. Безне хөрмәтләп, хурламыйча, рәхмәтеңнән мәхрүм итмәсәнә, имансызларны безгә ирекле кылмасана, бездән разый булсана", – дип дога кылды. Аннары Аллаһның Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәллам әйтте: "Әле генә Аллаһы Тәгалә миңа ун аять иңдерде. Әгәр бер кеше бу аятьләрдә әйтелгән сүзләрне үтәсә, ул кеше, шиксез, җәннәткә керер", – диде.

Мөхтәрәм җәмәгать! Пәйгамбәребезнең холкы – Коръән иде. Анда нәрсә әйтелгән булса, шул аның күңелендә булды. Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгалә шулай кылды, чөнки ул галәмгә рәхмәт итеп җибәрелгән зат иде. Шул турыда хәзрәти Гайшәдән: "Рәсүлуллаһыбызның холкы, халык белән мөгамәләсе нинди булды?" – дип сорадылар. Гайшә "Мөэминун" сүрәсеннән аять укыды да: "Пәйгамбәрнең холкы шул иде", – диде. Ул аятьләрдә әйтелгән холык Пәйгамбәребезнең калебенә урнашкан иде. Шулай булгач, мөхтәрәм җәмәгать, Пәйгамбәрнең юлыннан барабыз икән, аннан, һичшиксез, әз генә дә тайпылырга ярамый. Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезгә Кыямәт көнендә шәфәгатьче булу хокукын бирде. Һичшиксез, шәфәгать кылачак, насыйп булса. Аңа лаек булыр өчен үзебезне тәрбияләргә кирәк, югыйсә теләсә ни кылып йөрсәк – булмас.

Хәзер инде шушы аятьләрне укыйбыз, Аллаһы Тәгалә аларны күңелләребезгә беркетсә иде. "Мөэминун" сүрәсенең беренче аяте: "Дөреслектә, мөэминнәр Аллаһның газабыннан котылдылар", ягъни, җәһәннәмнән, мәңгелек газаптан. Моннан да зур табыш юк, мөхтәрәм җәмәгать. Дөньяда зур зарар күрсәң дә, Аллаһы Тәгаләнең газабы белән чагыштырганда ул берни дә түгел. Мөэминнәр хак юл таптылар, ягъни җәһәннәмнән котылдылар. Нинди мөэминнәр соң алар? Алар шундыйлар: намазларын Аллаһы Тәгаләдән куркып, тәннәре белән калтырап укыйлар, Раббыларына бәндәчелекләрен күрсәтәләр. Намаз эчендә кирәкмәгәнне уйламыйлар. Аллаһы Тәгалә безгә намазны фарыз итте, мөхтәрәм җәмәгать. Ул безнең Пәйгамбәребезне җиде кат күккә менгереп, аңа фәрештәләрнең гыйбадәт кылганнарын күрсәтте. Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәллам Аллаһы Тәгаләдән сорарга мәҗбүр булды: "Йә, Раббым, шушы фәрештәләрнеке шикелле өммәтемә дә бер изге гыйбадәт бирсәң иде дә, шуны кылып җәннәткә керсәләр иде", – диде, шуның өчен Аллаһы Тәгалә намазны бирде.

Намаз укучы кешегә нинди булырга кирәк? "Намазны торгызыгыз, намаз бозык һәм начар эшләрдән тыя", - диде Аллаһы Тәгалә. Ни дигән сүз бу? Укылган намазы бушка китмәсен өчен гыйбадәт кылучы берни дә бозыклык эшләмәскә тиеш була. Намаз ул – нур, "ассалятун-нур", – диде Рәсүлуллаһ. Намаз – диннең терәге, ул – мөэминнең нуры, намаз – мөэминнең мигъраҗы – күккә ашуы. Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәллам гомерендә бер мәртәбә күккә ашты. "Йә, Раббым, мөэминнәр мин үлгәч бозылырлар, харап булырлар", – дигәч, Аллаһы Тәгалә (белеп тора бит) Җәбраил галәйһиссәламне җибәрде. "Бар, Пәйгамбәрне тынычландыр. Мөэминнәр намаз укыганда, Аллаһы Тәгалә белән сөйләшеп торалар, тагы нәрсә кирәк инде", – диде Аллаһы Тәгалә. "Өммәтләрең намаз укыйлармы?" – диде Аллаһыбыз. "Укыйлар", - дип җавап бирде Пәйгамбәребез. "Һәр намазда "Фатиха" сүрәсен укыйлармы?" – дип сорагач: "Укыйлар", – диде. "Тагын нәрсә кирәк инде? Син гомереңдә бер мәртәбә Аллаһы Тәгалә белән сөйләштең. Ә алар һәр намазда сөйләшәләр", – диде. Чөнки, мөхтәрәм җәмәгать, һәр рәкәгатьтә без "Әлхәм"не укыйбыз ич.

"Әлхәм" бит ул – бөтен галәмнәрнең тәрбиячесе булган затка мактау. "Әр-Рахман" сүзе бөтен дөньяга рәхмәт кылучы дигәнне аңлата. Дөнья – сынау йорты ул, ә анда ашатмыйча ярамый. Аларның ашаганнары хакын түләү – киләчәктә. Ә без бүген, әлхәмдүлилләһ, түлибез – акча белән түгел, ә намаз уку, ураза тоту, сәдака бирү, хаҗ кылу белән. Аллаһның кадерен белү, бозыклыклардан саклану – менә шушы инде җәннәтнең билеты, аның хакы бу. Аннан калган кешеләр нигъмәтләрне ашасалар да, хакын түләмиләр, аны киләчәктә бирәчәкләр. Аллаһның менә шул рәхмәте бөтен халыкка, төрле диндәгеләргә ирешеп тора. Ашатмасаң, Кыяматтә сүз табачаклар: "Йә, Раббым, Син үзеңне бөтен бәндәләргә Гадел хаким дип әйттең, кайда синең гаделлегең? Безне дөньяда да ашатмадың, монда да җәһәннәмгә кертәсең?" Шундый сүзләр булмас өчен Аллаһы Тәгалә аларны ашата, ризыкларын бирә. "Әр-Рахим" – ахирәттә мөэминнәргә генә рәхим кылучы – ул Аллаһы Тәгалә, чөнки мөэминнәр Аллаһтан килгән һәрбер әмерне үтәүчеләр. Без дә үтәргә тырышабыз, әлхәмдүлилләһ. Раббым Аллаһ киләчәктә дә шулай яшәргә насыйп итсә иде.

Хисап көненең хуҗасы – Ул, ягъни Аллаһы Тәгалә. Дөньядагы бөтен хуҗалар барысы да вәйран булачаклар. Аллаһы Тәгалә кодрәт кулы белән җирне тотачак та: "Йә, бәндәләрем, кем хуҗа икән-

# ХОЛЫК

леген бүген аңладыгызмы?” – диячәк. Анда: “Әйе, әйе”, – дип баш ияргә генә кала. Аннары әйтәбез: “Йә, Аллаһ, Синең гына бәндәчелек күрсәтәбез, Синең гына гыйбадәт кылабыз. Синнән генә ярдәм эстибез. Дөнья вә ахирәт көнендә башканы түгел”, – дип Аллаһка бөтен вөҗүдебез белән мөрәҗәгать итәбез. Менә шуннан соң Аллаһы Тәгалә: “Йә, бәндәм, мине тиешле сыйфатларым белән сыйфатладың. Мин синнән разый булдым”, – дип әйтер икән.

“Туры юлга күндерсәнә”, - дибез. Берәү туры юлга күндеме, ул җәннәткә керде, дигән сүз.

“Кайбер бәндәләреңә үз рәхмәтең белән пәйгамбәрлек дәрәҗәсе бирдең, менә шуларның юлына безне күндерсәнә”, пәйгамбәрләр юлына.

“Адашканнар, Синең ачуың төшкән бәндәләрең юлыннан башка юлга күндер”.

Шуннан эчтән генә “Әмин” дип әйтәбез. Менә, мөхтәрәм җәмәгать, моннан да зур бәхет-сәгадәт булырга мөмкинме икән?! Без һәркөнне Аллаһы Тәгалә белән сөйләшеп торабыз икән, һәр рәкәгатендә ялварабыз.

Инде “Мөэминун” сүрәсенең өченче аятенә күчәбез. “Мөселманнар – шундый кешеләр: ни дөньясына, ни ахирәтенә файдасыз булган сүздән сакланалар, кирәкмәгән сүздән тыелалар”. Юкбарны сөйләү ни эш бу? Югыйсә намаз уку – аяк арыту гына булып кала түгелме соң?! Моңардан бик сакланырга кирәк.

Аннан соң, Аллаһының җәннәтенә керүчеләр – зәкят бирүчеләр. Аллаһы Тәгалә адәм баласына салым өстәде. Беркем дә бу салымнан гаеп таба алмый – шулкадәр ансат салды. Әгәр берәүнең 1000 сумы бар икән, 25 тәңкәсен зәкят итеп бирергә тиеш, әмма 12 ай үткәннән соң гына. Ул вакытка кадәр зәкят соралмый. Моны башкаручылар – зәкятне үтәүчеләр була. Зәкят - аклык дигән сүз, димәк, моннан калган мал пакь була. Аллаһы Тәгалә калганын урланудан да, югалудан да саклый. Аллаһы Раббыбыз һәркайсыбызга тәүфыйклы гамәл бирсә иде.

“Мөселманнар - шундый кешеләр: алар Аллаһның җәннәтенә керүчеләр, гаурәт әгъзаларын күрсәтмәсләр вә зинадан сакланырлар. Мәгәр үз хатыннарыннан вә җариялардән сакланмаслар. Берәү үз хатыныннан вә җариясеннән башканы эстәсә, ягъни зина кылса, ул хәләлдән хәрамга үтүчедер”. Зина – нәселне бетерә торган нәрсә. Ни өчен аны Аллаһы Тәгалә харам иткән соң? Чөнки хатынкызга нинди орлык салсаң, шундыйны үстерә. Мәсәлән, мин орлык салсам, миңа үстереп бирә. Син салсаң – сиңа. Әмма ике кешенең орлыгы бер карында булырга тиеш түгел. Аллаһы Тәгалә баланы безгә ни өчен бирә? Әманәт итеп бирә, үзебез шикелле мөселман итеп тәрбияләргә. Тудырып, ташлап качар өчен түгел. Шулай булмаса, Аллаһы Тәгалә нык газап кылачак, шуңа күрә бер хатынга ике ир белән торырга ярамый, ә бер иргә ике хатын белән никахлы яшәү рөхсәт ителә. Һәрбер ир үз орлыгын үзе тәрбияләргә тиешле, әмма ике ирнең орлыгы керсә, кайсы кемнеке икәнлеге билгеле булмый һәм ул бала зинадан туган була. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә зинадан сакланырга кушты. Сез бу гөнаһка якын килмәгез, чөнки ул – кабахәт, нәселне бетерә торган гамәл. Зинадан туган балада ата-ана шәфкате юк, аларны танымый да ул, ерткыч булып үсәчәк, шуңа күрә Аллаһы Тәгалә зинадан, хәтта аңа чакыра торган нәрсәләрдән дә бик сакланырга кушты.

“Җәннәткә керергә тиешле кешеләр – шундыйлар: әманәткә хыянәт кылмаучылар”, - ди Аллаһы Тәгалә. Әманәтне үтәү – ул сүз биргән икән, үтәргә тиешле. Берәү сиңа әманәт бирсә (сүз яки әйбер беләнме), син аңа хыянәт кылмаска тиешле. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: “Монафыйк кешенең галәмәте өчәү: беренчесе – сөйләгән вакытта ялганлау – дөрес сүз сөйләмәү; икенчесе – вәгъдә итсә, үтәмәү; өченчесе – әманәт тапшырылса – аңа хыянәт кылу”. Мондый эшләрдән сакланырга кирәк, чөнки ул гамәлләр – монафыйкларга гына хас.

Аллаһы Тәгалә кылган намазларыбызны кабул итеп, күркәм сыйфатлар белән сыйфатланырга насыйп итсә иде. Аллаһның рәхмәтендә булырга тиешле кешеләр – шундыйлар: намазларында дәвамлы булалар, ягъни атнасына бер җомгага гына килеп, гаетләрдә ишек төбендә тәмәке тартып кына китмичә, биш вакыт намаз укыйлар. Намаз фарыз кылынган икән, ул бервакытта да өстебездән төшми, җәмәгать. Намаз – ул, беренчедән, чисталыкка сәбәп, икенчедән, чисталык – сәламәтлеккә сәбәп, өченчедән, Аллаһының нуры. Намаз – диннең терәге. Йә, Раббым, гыйбадәтләрне үтәргә насыйп булса иде.

Мөселманнар кемнәр алар? Намазны ихластан укучылар, кирәкмәгән сүздән тыелучылар, зәкятне түләүчеләр, гаурәтләрен күрсәтмәүчеләр, зинадан сакланучылар, әманәттә торучылар, биш вакыт намазны үтәүчеләр. Болар – варислар инде, ди Аллаһы Тәгалә. Ата-ана малына хокуклы кешеләр гарәп телендә “варис” дип атала. Әти-әниләре үлеп, маллары калса, шуңа хуҗа булып калучылар, ә малны – мирас диләр. Менә шушы 7 төрле сыйфат белән сыйфатланучылар – варислар, ди Аллаһы Тәгалә, ягъни малга хуҗа булучылар. Шундый варислар алар, җәннәтне мирас итеп алалар, ди. Йә, Раббым, барыбызга да җәннәтле булырга насыйп итсәң иде.

Алар – анда мәңге калучылар. Без бу дөньяда һәрвакыт үлемнән куркабыз, анда нәрсәләр булыр икән, дип уйлыйбыз. Җәннәттә исә, үлемнән курку юк, анда үлем булмый. Без һәм хатыннарыбыз 33 яшендә булачакбыз. Бу Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тәгълиме. Яшь тә түгел, карт та түгел, иншә Аллаһ. Йә, Раббым, бу шатлыклар барыбызга да насыйп булса иде. Без – иманлылар, шул иманыбыз мәчеткә китерде. Иманыбыз булмаса, без монда килер идекме? Кимчелекле булса да, үзебездән һәм балаларыбыздан Аллаһы Тәгалә укылган намазларыбызны кабул итсә иде.

Шушы әйтелгән сыйфатларны үзебездә булдырсак, Аллаһы Тәгаләнең мактавына, Кыямәт көнендә Аның рәхмәтенә ирешербез, иншә Аллаһ.

Аллаһы Тәгалә бөтен пәйгамбәрләрне исеме белән атады. Коръәндә адәм галәйһиссәламгә: “Йә, Адәм, үзең дә, хатының да җәннәттә торыгыз”, - диде. Нух галәйһиссәламне дә: “Йә, Нух галәйһиссәлам”, - дип үзенең исеме белән атады. Ибраһим галәйһиссәламгә дә: “Йә, Ибраһим галәйһиссәлам, улыңны корбан итеп чал”, – дип әйтте. Аллаһы Тәгалә улы Исмәгыйльне бугазлатмады. “Мин адәм балаларын җир йөзенә хөрмәтле итеп яралттым”, – диде. Аллаһы Тәгалә хөрмәтле итеп яралткан бәндәләренең тиресен тунатып, итен безгә ашатамы соң?! Адәм баласына корбан чалу өчен тиешле хайваннарны яралтты. Кешеләргә дөньяда хәлифә дәрәҗәсен бирде. Ибраһим галәйһиссәламгә улын корбан чалуны сынау өчен генә кушты. Аллаһы Тәгалә аның үтәячәген белде. Аллаһы Тәгалә аның төшендә әйтте:”Балаңны нәзер белән алган идең, “Йә, Раббым, үз урынымда калырлык бер бала бирсәң, Синең юлыңда бугазлармын”, – диган идең, оныттың”. Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламнең исенә төшерде. Ибраһим галәйһиссәлам баласы Исмәгыйль галәйһиссәламне Аллаһ әмеренә буйсынып, корбан итәргә әзерлеген күрсәтте, тик Аллаһы Тәгалә рөхсәт бирмәде.

Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәламне, Давыт галәйһиссәламне, Зәкәрия галәйһиссәламне исемнәре белән атады. Зәкәрия галәйһиссәламнең, яше йөздән узгач, баласы туды, исеме – Яхъя. Ул Пәйгамбәргә дә Аллаһ: “Йә, Яхъя”, - дип исеме белән әйтте.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә: “Йә, Пәйгамбәр, Минем тарафымнан сиңа ирешкән Коръәни Кәримне өммәтеңә ирештер, алай итмәсәң – пәйгамбәрлек вазыйфасын үтәмәгән булырсың”, – диде Аллаһы Тәгалә. “Ничек ирештерим соң, Раббым, бу халыкны ничек дингә кертим?” – диде Пәйгамбәребез. Бер ялгызы бит ул, аңа күпме җәфа күрсәттеләр. Аллаһы Тәгалә шул вакытта әйтте: “Раббың сине адәмнәрдән саклый шуңа ышан да минем тарафымнан ирештерелгән Коръәнне аларга җиткер”. Кыямәт көнендә аның шәфәгатенә ирешергә насыйп булса иде. Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезне Коръәндә “нәби” дип атады. “Әй, Пәйгамбәр, без сине өммәтләреңә шаһит иттереп, җәннәт белән сөендерүче, җәһәннәм уты белән куркытучы буларак җибәрдек. Аллаһның исеме белән Аллаһ юлына чакыручы итеп җибәрдек”.

Шулай ук Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезнең гакылын да саклады, мөшрикләр: “Ул җенле, ул акылыннан адашкан”, – дисәләр дә, адашмады, акылыннан чыкмады. Аллаһы Тәгалә аның телен дә пакьләде. “Ул үз теләге белән сөйләми”, – диде. Шәригатен дә пакьләде: “Аңа мөкатдәс Коръән минем тарафымнан Җәбраил фәрештә аркылы ирештерелде”, – диде Аллаһы Тәгалә. “Бу Коръәнне алыштыр, бу – синең Коръәнең”, – дип кяферләр әйтсәләр дә, Аллаһы Тәгалә аны алыштырырга кушмады. Шуның белән бергә, аңарга Коръәнне өйрәткән затны да, Җәбраил фәрештәне дә күрде Пәйгамбәребез. Шулай ук Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезнең калебен дә пакьләде. Күзен дә сафлады Аллаһы Тәгалә: Пәйгамбәребезнеңкүзехакыйкатьтән авышмады.

“Әй, Пәйгамбәр, хакыйкатьтә, син иң олуг холыкта”, – диде Аллаһы Тәгалә, ләкин бик масаеп китмәсен өчен: “Син, Пәйгамбәрем, Минем рәхмәтем аркасында күркәм холыклы булдың”, - дип әйтте. Ул аны 40 яшенә җиткәнче мөшрикләрнең – бәдбәхетләрнең әшәкелегеннән саклап тәрбияләде.

“Әгәр чытык йөзле, каты күңелле булсаң, синең яныңа җыелу түгел, килмәсләр дә иде, таралырлар иде”, - диде Аллаһы Тәгалә. Аңа Коръән иңә башласа, сәхабәләр бу аятьне өйрәнмичә өйләренә китмиләр иде. Менә шулай дин таралды, мөхтәрәм җәмәгать. Әле без “Колхуаллаһу”ны да укырга теләмибез. “Булмый бит, хәзрәт,” – дибез. Тырышмагач, ничек булсын ул? Без, адәм баласы, булдырмаган нәрсә бармы, җәмәгать? Эш шунда – теләк юк. Ул булмагач, без ничек галим булыйк? Балаларыбызны ничек өйрәтә алырбыз? Алар безгә әманәт итеп бирелгән бит, балалар өчен без җаваплы. Аларга иман кәлимәсен дә, яхшы гореф-гадәтләрне дә өйрәтергә тиешбез. Безгә хәдисләр кирәкми, Коръән булса, шул җиткән, диючеләр бар. Алар турында Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: “Кыямәт көне алдыннан шундый кешеләр булыр, минем хәдисләремне инкарь итәрләр”, - диде. Динебезнең нигезе – Коръән, хәдис. Коръәндә булмаган нәрсәләр хәдисләрдә бар. Без шулар белән гамәл кылабыз. Йә, Раббым, күңелләребезгә иман нуры салып, яхшы гамәлләр кылып, барыбыз да җәннәт әһеле булсак иде.

# Бөрбашта кабат очрашулар насыйп булсын!

**Халкыбызның милли бәйрәме - Сабан туен мөселманча итеп, ягъни шәригатькә туры китереп уздыру сигез ел элек балтачлылардан башланган иде. Күркәм үрнәкне байтак районнар күтәреп алды. Халык хәрам эчемлекләрсез, матур итеп бәйрәм итәргә өйрәнеп килә, шөкер. Быел мөселман Сабан туйлары Кайбыч, Әтнә, Арча, Саба, Ютазы районнарында да узды. Ә Балтач районы Бөрбаш авылындагысының даны инде республика чикләреннән үтеп, бөтен Россиягә таралды.**



Иртән торырга өйрәнгән Бөрбаш халкы сәгать 5 тулганчы үзәк урамнан төрле җиһазлар төягән машиналарның тыз да быз чабуын күргәч, бүген бездә бәйрәм бит әле дип, хуҗалык эшләрен төгәлләргә ашыкты, кунаклар каршы алырга әзерләнә башлады. Балалар Сабан туе гына дип аталса да, гадәти түгел ул. Бу көнне Бөрбаш халкы бәйрәм уңаеннан туганнарын, якыннарын һәм бик күп кунаклар кабул итә. Әлеге күркәм бәйрәмнең тарихы турында Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев болай дип сөйли:

– Сигез ел элек, бу бәйрәмне үткәрә башлаганда, районыбызда Сабан туйлары аракысыз узмый иде. Ул вакытта кешеләрдә хәмердән башка бәйрәм итеп, күңел ачып булмый, дигән фикер шуның кадәр ныгыган иде, аны үзгәртү мөмкин булмастай тоелды. Мөселман Сабан туе дип башлап җибәрүебез дә шул ялган фикердән арындыру ниятеннән иде. Ә ни өчен балалар Сабан туе? Без, балалар – безнең киләчәгебез, дип кабатларга яратабыз, ә киләчәк турында бүген кайгыртмыйбыз. Һәркем баласының тәрбияле, эчми-тартмый торган булуын тели. Тәрбияне ислам дине аша бергәләп алып барсак, моңа ирешү җиңелрәк бит. Бу бәйрәм башка балаларны да кимсетми, катнашасың һәм бүләк аласың килә икән, үзебезчә киен, Коръән аятьләре, сүрәләрен ятла, сөйлә, башкалар алдында үзеңне бу яктан да күрсәт. Аннан соң иң әһәмиятлесе – безнең балалар аралашырга, бер-берсе белән танышырга, үзләренең татар, мөселман балалары булганнары өчен горурланырга да тиешләр.

Корьән уку белән башланып киткән бәйрәмдә, балалар да, олылар да күп иде. Күрше районнардан гына түгел, ераклардан ук килгәннәр – барлыгы 5 меңнән артык кеше җыелды. Ульяновск өлкәсеннән, Мари Иленең Мари Төрек, Бәрәңге районнарыннан, Киров өлкәсенең Малмыж, Нократ Аланы районнарыннан кунаклар хәйран иде. Балалар белән бергәләп, олылар да рәхәтләнеп бәйрәм итте, үзара аралашты.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Сабан туенда катнашучыларга үзенең теләкләрен җиткерде: "Пәйгәмбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә әйтелгәнчә, аралашу, очрашу, бергәләп фикерләшү мөселман кеше өчен бу дөньядагы 3 зур шатлыкның берсе булып тора. Бу зур бәйрәмдә мин шатланып катнашам. Балтач җирлегендә, Бөрбаш авылында мондый мәртәбәле бәйрәм тагын күп еллар дәвам итсен иде". Нурлат районы мөхтәсибе Айрат Әюпов: "Балтачтан ерак, республиканың икенче читендә урнашкан булсак та, бу Сабан туена икенче тапкыр киләм. Иманлы як булгач, Аллаһы Тәгалә сезнең якка яңгырын да биргән, игеннәрегез дә күкрәп утыра, уңышы да куанычы белән булсын! Районыбызга кайткач сокланып сөйлим, булдырасыз!"- диде ул.

Сабан туеның уңышлы баруы аның хәзерлегеннән тора. Оештыручыларга эчкерсез булышып йөргән Гөлсем Миннебаеваның бу турыда үз фикере бар. "Хәзерлек чорында күп көч куелды. Бүләкләрен, алып барышын, чыгышларны әзерләүдә Гүзәл Бариеваның исемен аерым атап китәргә кирәк, мәктәп директоры эшен генә алып бармыйча, авылны бергә туплауда аның да зур өлеше бар". Ярдәм итүчеләрнең исемлеге озын, аларның кайберләренә мәйданда рәхмәт хатлары, бүләкләр тапшырылды.

Олылар Сабан туенда булган барлык төр ярышлар да оештырылды мәйданда. Район башлыгы Рамил Нотфуллин 22 ат арасында чабышта җиңүчеләрнең җайдакларына шәхси призларын тапшырды. Чабышкылар ярышы һәм аны тамаша кылу өчен Бөрбаш хуҗалыгы махсус әзерләгән уңайлы урын югары бәяләүгә лаек.

Бәйге читендә ераклыкка сикерү, турникта тартылу, җирдән кулда этену, гер күтәрү буенча балалар, олылар арасында ярышлар бәйрәм буе барды. "Президент белән бергә" иҗтимагый хәрәкәтенең Балтач бүлеге оештырган бу чарада һәркем бик теләп катнашты.

Сабан туеның баш батырын да атап китик. Ул безнең якташыбыз, үзе дә заманында бәйге тоткан, татар дөньясында күренекле шәхес Фатыйх Сибагатуллинның улы Рөстәм. Узган ел бу егет көрәштә призлы урынга кереп, үзенең үҗәтлеге, җиңүгә омтылышы белән истә калган иде, быел менә – җиңүче. Бәйрәмнең күп санлы иганәчеләренең берсе әзерләгән иң зур бүләк – чит илдә эшләнгән скутер Рөстәмнеке булды.

Еллар имин булсын, киләсе елга да шушы матур урында яңадан очрашырга, шатлыклар белән бүлешергә насыйп итсен, дип барлык кешеләргә бәхет теләп, Сабан туе кунаклары бер-берсе белән эчкерсез хушлашты. Ә бәйрәм табыннар артында, Бөрбаш авылы өйләрендә әле караңгыга кадәр гөрләде.

**BALTACI.RU**

Болгар тюбетей



С древних времен у татар тюбетейка являлась неотъемлемой частью национальной одежды. Тюбетейка являлась не только простым головным убором, но и подчеркивала человека как скромного, благо-воспитанного, религиозно-послушного, верующего, раскрывала внутреннюю сущность человека, духовный мир его. Поэтому, о человеке истинно верующем, живущем по правилам Корана, говорили, что "он родился в тюбетейке".

У татар тюбетейку принято называть каляпуш. Каляпуш-слово фарси: «каля»-понятие головы, «пуш» - покрыть. То есть, «перед намазом накрой голову».

Тюбетейки отличаются друг от друга по шитью, орнаменту и вышивке. Повседневные мужские тюбетейки обычно шьют из черного бархата. Они вышиваются разноцветными шелковыми нитками, украшаются золотой или серебряной канителью, бусами, блестками, камнями, позже - бисером, стеклярусом, жемчугом.

Шьем разные виды тюбетеек-каляпуш, вышиваем и украшаем бисером и камнями, а также шьем женские тюбетейки, которых нет аналогов в продаже. Цены на тюбетейки доступны всем, начинаются от 185 рублей. Ждем вас, продажа оптом, в розницу и под заказ.

420021, РТ, г. Казань, ул. Тукая, д. 5. тел.: (843) 292-29-19 (раб), 8-987-296-62-42



# Ике бәйрәм бергә килде

**Ураза гаете көнне Мамадыштагы Әхмәт Ясәви мәчете ишегалдында мөселман балалар өчен Сабан туе бәйрәме үткәрелде. Кунакларның иң олысы– сабыйлар, бәйгеләр нәкъ менә аларның йөзләрендәге куанычны күрү, күңелләрендә шатлык хисләрен арттыру өчен оештырылган иде. Аны оештыруда “Ак калфак” мөслимәләр оешмасы җитәкчесе Рузалия Ибраһимова башлап йөрде. Рамазан ае дәвамында Әхмәт Ясәви мәчетендә һәр көнне 80 кешегә ифтар мәҗлесләре үткәрелде, тәравих намазлары укылды. Мөбарәк рамазан ае тәмамлангач, Ураза бәйрәмен күпләгән халык җыеп бәйрәм итү, бу уңайдан махсус Сабан туе оештыру хуплауга лаек гамәл.**



Балалар Сабан туен Әхмәт Ясәви мәчете имамы Нурислам хәзрәт Газизов алып барды. Ул: “Без рамазан дәвамында уразалар тоттык, гөнаһларыбызны кичерүне сорап догалар кылдык. Рамазан аенда иман белән һәм савапка ирешүгә өмет баглап, ураза тоткан кешенең элеккеге барча гөнаһлары да ярлыканыр, иншаллаһ. Раббыбыз, догаларыбызны кабуллардан кылса иде!”, – диде.

Бәйрәмне районыбыз мөхтәсибе Илһам Миннегалиев дәвам итте. Ул: “Хакыйкый мөселман кеше өчен җаваплылыкны тою – үзенең гаиләсен Аллаһы Тәгалә кушкан рәвештә тәрбияләү була. Әгәр мөэминмөселманга Аллаһы Тәгалә балалар бүләк итсә, ул аларны ислам рухында тәрбияләү өчен барлык нәрсәләргә дә игътибар бирергә тиеш”, – дип ассызыклады.

Шундый күңелле мизгелләрдә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Алена Смирнова килеп, мөселманнарны әлеге күркәм бәйрәм белән тәбрикләде.

Тәүге тапкыр үткәрелгән чарага мөгаллимнәр, лагерьга йөргән балалар, аларның атааналары, әби-бабайлары да җыелды. Рамазан ае дәвамында эшләгән лагерьда балалар күңеленә кыска вакыт эчендә зур тәрбия һәм гыйлем сеңдерелде. Алар хәләлне хәрамнан аерырга, намаз кагыйдәләренә, мөселманча тормыш рәвеше алып барырга, аларны хөрмәт итәргә өйрәнделәр. Лагерьда белем бирү максаты гына куелмады, ямьле җәй көннәрендә балаларның сәламәтлеген ныгытуга да зур игътибар ителде. Шунлыктан төрле хәрәкәтле уеннар оештырылды. Әлбәттә, дин сабакларын да өйрәттеләр. Аларга Рәшит Вәлиев, Гадилә Гәрәева, Әлфия Сингатуллина, Рузалия Ибраһимова, Рәсимә абыстай Гайнетдинова дәресләр бирде. Балалар Сабан туенда динебезгә багышланган шигырьләр, җырлар башкардылар, викторина сорауларына җавап бирделәр. Балаларның төпле җаваплары – укытучыларының тырышлыклары нәтиҗәсе. Шәһәребез мәдрәсәсе пешекчесе Рамил Кәримов викторина сорауларына дөрес җавап бирүчеләргә шәхси бүләкләрен тапшырып китте. Рамазан ае буе лагерьга йөргән 20 балага,

мөгаллимнәргә, җыештыручыларга, пешекчеләргә истәлекле бүләкләр тапшырылды.

Йөзләгән балаларның йөзләрендә шатлык, сөенеч хисләре балкыды. Кашыкка йомырка салып яисә капчык киеп йөгерү, җепкә эленгән бүләкне күз бәйләп кисү - ярышлар санап бетергесез иде. Барлык балалар да актив катнашты. Сабантуйга килгән кешеләр өчен бик тәмле пылау пешерелеп, зур мәҗлес әзерләнде. Ахырдан әти-әниләр, балалар мәчеттә өйлә намазын укып, җәмәгать белән дога кылды. Сабантуй ярышларында катнашып җиңүчеләргә бүләкләр тапшыруда һәм чәй табынын оештыруда үз өлешләрен керткән иганәчеләребезнең һәркайсына Аллаһының рәхмәтләре булсын.

**Фирая МИНГАЛИЕВА,**
**Мамадыш**

# Чын мөселманча Сабан туенда

**Мондый Сабан туе районда инде дүртенче ел рәттән оештырыла. Башка еллардагы кебек үк быел да ул Коръән аятьләре, дога һәм үгет – нәсыйхәтләр уку белән башланды. Казаннан килгән хөрмәтле кунак - Рөстәм Хәйруллинның вәгазен дә бәйрәмдә катнашучылар игътибар белән тыңладылар.**

Милли бәйрәмебезнең барлык уеннарын үз эченә алган Сабан туена райондашлар гына түгел, күрше районнардан, шәһәрләрдән дә кунаклар күп килгән. Аларны пылау, коймак, кайнар чәй белән сыйладылар. Полиция бүлегенең кыр кухнясында да тәмле карабодай һәм борай боткалары пешергәннәр, шашлыктан авыз итү мөмкинлеге дә бар иде.

Гадәти Сабан туйларыннан аермалы буларак, монда милли уеннар ике мәйданчыкта үтте. Берсендә ир–егетләр көч сынашса, икенчесендә – гүзәл затлар. Әмма иң кызыгы, мөгаен, балаларга булгандыр. Алар бөтен җиргә өлгерергә тырыштылар. Чүлмәк вату, капчык киеп, йомыркалы кашык кабып йөгерү, аркан тартышу, йөгерү кебек ярышларда бик күп бала катнашты һәм аларның һәрберсенә бүләкләр бирелде.

Ә инде олыраклар үзләрен җитдиерәк бәйгеләрдә сынадылар. Әйтик, гер күтәрүдә үз үлчәү категорияләрендә Түбән Кәминкәдән Тәлгать Закиров (70 килограммга кадәр), Керкәледән Салават Әхмәтвәлиев (80 килограммга кадәр) һәм Түбән Кәминкәдән Айваз Сәлманов (80 килограммнан югары) беренче булдылар. Кул көрәштерүдә дә Тәлгать Закировка, Салават Әхмәтвәлиевка һәм Түбән Кәминкә егете Разиф Гыйрфановка тиңнәр булмады. Һәрберсе үз үлчәү категориясендә җиңүче.

Көрәшчеләр арасында да чит кеше юк иде. Келәмгә чыгучыларга карата бер шарт та куелган: дин юлына баскан, мәчеткә тәравих намазына йөргән егетләр генә көрәшкә кертелде. Түбән Кама егете Азат Фәсхетдинов (әтисе Кара Чишмәдән) узган елны мөселман Сабан туеннан тәкә алып киткән булган. Быел да ул 70 килограммга кадәр авырлыктагылар арасында көрәштә беренче. Лашман егете Зөлфәт Зиннуров (80 килолылар арасында) һәм Разиф Гыйрфанов та (80 килодан авыраклар арасында) җиңүчеләр.

Хатын–кызлар су ташу, кашыкка



йомырка салып йөгерү кебек уеннарда катнаштылар. Иң оста Коръән укучыны да билгеләделәр.

Быел мөселман Сабан туенда атлар узышы да булды. Дүрт ат узышын карарга байтак тамашачы җыелды. Финишка Аксубай егете Нәфис Мингатин йөгәнләгән ат беренче килде. Чирмешәннән Геннадий Герасимов аты - икенче, Шәүкәт Тәхаутдиновныкы өченче урыннарда.

- Чирмешәндә узучы мөселман Сабан туена ел да кайтам, - ди Түбән Камада яшәүче Нурхаммәт абый Фәсхетдинов. - Сагынып кайтам. Миңа монда бик ошый. Шундый матур, тыныч уза ул. Бу традицияне киләчәктә дә дәвам итсеннәр иде.

Район мөхтәсибе Минсәгыйрь хәзрәт Миншин да бәйрәмнән бик канәгать калган.

- Имамнарыбыз, мәчеткә йөрүче дин кардәшләребез барын да үзләре оештырдылар, рәхмәт, Аллаһы Тәгалә исәнлекләрен бирсен, - диде ул.

**Гөлсирә ШӘРИФУЛЛИНА,**



ШКОЛА УСМАНИЯ
“Помоги своей школе “Усмания” подготовиться к новому учебному году
БЛАГОТВОРИТЕЛЬНАЯ АКЦИЯ!
тел. (843) 253 37 61, 8903 305 37 61
www.edu.tatar.ru e-mail: usmania@yandex.ru
Частное общеобразовательное учреждение «Средняя общеобразовательная школа «Усмания» г. Казани (ЧОУ «Школа «Усмания»). Адрес: 420047, г.Казань, ул. М. Бигиева, д.38
Реквизиты ЧОУ «Школа «Усмания»: ИНН 1661007222, КПП 166101001,
р/с 40703810100010000377 в Тимер Банк (ПАО),
к/с 30101810900000000798, БИК 049205798, ОКПО 50624415

# Болгар тәэсирләре белән яшәп ятыш

**Мөселман яшьләре форумына барырга җыенуымны белгәч, әни тәмам хафага төште. Һава торышы бозылырга тора, җылы киемнәреңне алырга онытма, дип кат-кат тукыды. Бер дә юкка борчыла инде. Ялыктыргыч фестиваль булса, үземнең дә анда озак торкарланырга исәбем юк...**



Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Болгарда оештырган Мөселман яшьләре форумына мин әнә шундый уйлар белән килгән идем. Изге Болгар җирләренә аяк басуга без - илнең төрле төбәкләреннән җыелган 100 дән артык мөселман-татар баласы форум тормышына кереп чумганыбызны сизми дә калдык...

Ул көннәрдә Казан – Болгар юлына тузан кунмады. Юк вакытын бар итеп, безнең белән очрашырга Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзе дә килеп китте. Форумда катнашучылар арасында Коръән уку конкурсы уздырылды, җиңүчеләр мөфти хәзрәт кулыннан бүләкләр алдылар. Әнә шундый яшьләр җыелган иде форумга. Күбесе дини-дөньяви уку йортларында белем ала, һич тә дини нәсыйхәткә сусаган, дип әйтә торган түгел. Әшулай да лекцияләрне йотлыгып тыңлыйбыз, чөнки хәзрәтләр безнең телдә, безне кызыксындырган нәрсәләр турында сөйлиләр. Мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллинның гаиләк ыйммәтләренә багышланган лекциясе дә бик әһәмиятле һәм кызыклы иде. Хәзрәт килгән саен хәлләребезне белешеп, торак шартларын барлап, безне аталарча кайгыртып торды. Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин турында исә гыйлемле, кабатланмас шәхес дигәннәрен ишеткән бар иде. Беренче сүзләреннән үк ул безне авызына каратты да куйды.

Мастер-класслар да нәкъ менә безгә кирәкле темаларга багышланган иде. Куйган максатларга ничек ирешергә, вакытны ничек дөрес кулланырга, зур публикада чыгыш ясаганда каушап калмас өчен нәрсәләр эшләргә икәнен өйрәндек. Һәрбер мастер-класс, лекцияне бөртекләп дәфтәрләребезгә теркәп бардык. Лекция дигәч тә, уку йортларындагы йокыны китерә торган лекцияләр түгел, киресенчә, игътибарыбызны тулаем җәлеп итеп алган, күнелле һәм кызыклы дәресләр иде алар.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм нәселеннән булган ислам фәннәре белгече Габдрәхим Ләкрим белән очрашулар мәңге онытылмас. Аның белән сөйләшеп сүзләребез, биреп сорауларыбыз бетмәде. Тагын бераз аралашсак, мөгаен, тәрҗемәченең кирәге дә калмас иде. Шундый затлы нәселдән чыккан, олуг дәрәҗәләргә һәм матди байлыкка ирешеп тә, аның гаҗәеп дәрәҗәдә гади һәм ихлас булып калуы тәмам әсир итте. Һәр кичне ул безне: “Мин монда ял итәргә түгел, гыйлемем бирергә килдем”, - дип каршылый иде. Ястүдән соң, арыганлыгыбызны онытып, Ак мәчеткә шәех янына йөгерәбез. Беренче көннәрне авыз ачарга да оялып утырсак, атна ахырына сорауларыбыз бетмәс булды, ә ул һәрберсенә сабыр гына җавап бирә. Нәкъ менә шунда гыйлем таләп итүнең асыл мәгънәсен аңладык, иң кыйммәтле дәресебезне алдык.

Диния нәзарәтенең яшьләр бүлеге нинди генә уеннар, мәдәни чаралар әзерләмәгән безнең өчен. Күптән инде – балачактан бирле футбол уйнаган юк иде. 18 яшьлекләребез дә, 30 га җиткәннәр дә рәхәтләнеп туп типтек. Күңелләре нечкәреп китеп, кайбер кызларыбыз шигырьләр дә иҗат итте. Кырымтатар кардәшләребезнең исә безне бик тә үз мәдәниятләре белән таныштырасы килде, җырлап та бирделәр, биеп тә күрсәттеләр, музыка уен коралларе юк, дип тә аптырамадылар – судан бушаган шешәләр эшкә җигелде. Шулкадәр дуслаштык үзләре белән, күз яшьләрен түгеп, бирегә тагын киләбез әле, дип саубуллаштылар. Болгарда тапкан дуслар белән аерылышу безгә дә бик ямансу булды. Һаман да шунда алган тәэсирләр белән яшибез, челтәрдә аралашабыз, сөйләшеп сүзләр бетми, форумлы җәй әле дә дәвам итә.

**Айзилә КӘБИРОВА**

# Кабан күле буенда “Печән базары” гөрләде

**Казанның Шиһабетдин Мәрҗани урамында быел да “Печән базары” фестивале гөрләде. Әлеге ярминкә-фестиваль Бөтендөнья татар яшьләре форумы, ТР Мәдәният министрлыгы, Казан шәһәре башкарма комитеты, “Иске шәһәр” префектурасы, Бөтендөнья татар конгрессы һәм Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры тарафыннан оештырылган иде.**




Традицион ярминкәдән тыш быел җәмгысе 15 ләп мәйдан эшләде. Аерым алганда, уку паркы, шигъри слэм, граффити-фест, әдәби квест, төрледән-төрле мастер-класслар, “Исән!fest” рок-фестивале һ.б. чаралар оештырылды. Чарада катнашкан һәркемгә XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы чоры киемнәре, көнкүреше белән танышу мөмкинлеге булдырылды. Фестиваль казанлыларга һәм башкала кунакларына татар дизайнерлары, һөнәрчеләре, тегүчеләре, кул эшләре осталары иҗатларын танытуны да күз уңында тота.

Көндезге 3 тә эшли башлаган ярминкәдә Казан, Мәскәү, Уфа, Ижевск һәм Пермь осталары тарафыннан милли төсмерле өс киемнәре, түбәтәй-калфаклар, читек-кәвешләр, бизәнү әйберләре, кул эшләнмәләре, шәмаилләр, уенчыклар, һ.б. бик күп әйберләр тәкъдим ителде.

Фестивальнең уку паркы территориясендә укырга яратучылар өчен татарча китаплар тезелгән киштәләр тәкъдим ителде, шулай ук сирәк очрый торган татар китаплары буккросингы һәм әдәби квест оештырылды. ТР Милли китапханәсе чарада катнашучылар арасында Г.Тукайның иҗаты һәм тормыш юлына багышланган викторина уздырып, бүләкләр өләште. Бирелә үк республиканың татар телендә чыга торган журналларына язылу, аларны сатып алу мөмкинлеге булдырылган иде.

Уку паркында кичке 6 да шигъри слэм башланып китте. Аны “Калеб” иҗади төркеме оештырды. Слэм – шигырь уку буенча көч сынашуның заманча форматы. Монда, шигъри әсәрләрнең сыйфатыннан тыш, аларны башкару рәвеше дә әһәмияткә ия. Слэмда катнашучылар үзләре иҗат иткән әсәрләрне яттан сөйләде.

“Печән базары” кунакларына шулай ук “Кисекбаш” юл күрсәткече таратылды. Әлеге юл күрсәткеч Габдулла Тукайның “Печән базары, яки Яңа кисекбаш” поэмасы мотивлары буенча эшләнгән һәм аны кулына алган һәркем әсәрдә сурәтләнгән тарихи урыннарның хәзер ничек аталуы турында мәгълүматлы булды. Фестивальдә катнашучыларга татар телендә фән, белем һәм мәгърифәт турындагы “Гыйлем вә фән” газетасы таратылды. Анда яшүсмерләр арасында бик популяр булган Гарри Поттер әсәренең беренче бүлегенең татарчага тәрҗемәсе урнаштырылган иде. “Печән базары” кысаларында “Сабыйлар” балалар мәйданчыгы, әдәби фотозона, татар хәрефләреннән инсталляция, ирекле микрофон, төрле мастер-класслар оештырылды.

Тәмле почмакта кунаклар өчен татар милли ризыклары белән чәй эчү, шулай ук татар кондитерлары пешергән тәм-томнардан авыз итеп карау мөмкинлеге булдырылган иде.

**TATAR-INFORM**

**Кайный тормыш. Редакция почтасына килгән хат-хәбәрләргә күз салуга моның шулай булуына инанасың**

# Дини белем сукмагында очрашырга насыйп булсын

**Балаларның җәйге ялларын файдалы итеп оештырырга тырышканнар байтак мәхәлләләрдә. Кукмара мәдрәсәсендә ачылган җәйге мәйданчыкка әнә 88 бала йөргән.**



Балаларга махсус төзелгән программа буенча дәресләр бирелгән, вәгазьләр сөйләнгән. Алар өчен шулай ук төрле уеннар, конкурслар, мәдәни чаралар һәм хәләл туклану да оештырылган. Мәйданчыкка бер дога, бер гарәп хәрефен дә белмичә килүчеләр дә тәһарәт алырга, намаз тәртибен, гарәп әлифбасын өйрәнеп киткәннәр. Белем алуда уңышка ирешүчеләр өчен 1, 5, яки 10 баллы "Тырыш шәкерткә" дип исемләнгән медальоннар бирелеп барылган. Иң күп балл җыючыларга, шулай ук дини рәсем, мәйданчык турында иң яхшы язма конкурсларында призлы урынга лаек булучыларга соңыннан бүләкләр дә тапшырылган. Сабуллашканда остазлары балаларны: "Дини белем сукмагында очрашырга, аралашып яшәргә насыйп булсын!" – дип дога кылып озатып калганнар.

Хәбәрләргә караганда, шушындый балалар мәйданчыклары байтак мөхтәсибәтләрдә оештырылган быел. Тукай районы мөхтәсибәтенең Малтабар, Теләнче Тамак, Калмаш мәхәлләләрендә, Минзәлә мөхтәсибәтенең Минзәлә һәм Иркәнәш мәхәлләләрендә дә балалар мәйданчыклары эшләгән. Минзәлә районында 42, Тукай районында 56 бала шул мәйданчыкларга йөреп, динебез турында белем алган, төрле кызыклы чараларда катнашып, каникул көннәрен файдалы итеп үткәргән.

Шулай ук Арча һәм Олы Әтнәнең җамигъ мәчетләре каршында да балалар мәйданчыклары дистәләгән баланы үзенә җыеп, аларга дини белем һәм тәрбия биргән, әдәп-әхлакка өйрәткән, алар өчен төрле мавыктыргыч уеннар оештырган.

Азнакай шәһәренең Ак мәчетендә, Зәңгәр мәчеттә, Әсәй, Чалпы, Кәкре Елга авыллары мәхәлләләрендә оештырылган мәйданчыкларда да балалар дини-әхлакый тәрбия алган, гарәп телен, Коръәни Кәрим аятьләрен өйрәнгән. Программада шулай ук спорт ярышлары, мастер-класслар, төрле экскурсияләр һәм конкурслар каралган булган.

Чирмешән мәчете каршындагы мәйданчыкта төрле яшьтәге 25 кыз бала Коръән аятьләрен өйрәнгән, ислам этикасы белән танышкан, "Ата-анага хөрмәт" һәм "Мөгаллимнәргә нинди мөнәсәбәттә булырга?" дигән темаларга лекцияләр тыңлаган. Кызлар өчен күңел ачу программасы да оештырылган. Аларны бассейнга, боз сараена һәм хәтта ипи пешерү комбинатына алып барганнар.

Кайбыч районы мөхтәсибәтенең Олы Кайбыч, Кече Кайбыч, Иске Чәчкәб, Чүти, Олы Кошман, Түбән Кошман, Борындык, Олы Урсак, Ябалак мәхәлләләрендә дә балаларга дини сабаклар биргәннәр, пәйгамбәрләр тарихын сөйләгәннәр, намаз укырга өйрәткәннәр. Шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге һәм беренче сыйныфны гына тәмамлаган балалар өчен "Әниемнең догалары" дигән бәйге дә оештырылган.

Авыл җирлегендәге кебек табигать кочагы, иркенлек булмаса да, Казанда да берничә мәхәллә даими рәвештә каникул көннәрендә балаларның ялларын дөрес һәм файдалы итеп оештыруга үзләреннән өлеш кертә. Бу юлы Кабан арты мәчете мәхәлләсе кыз балаларны "Туры юл" дип аталган мәйданчыкка җыйды. Алар өчен мәдәни-күңел ачу һәм уку программасы әзерләнгән иде. Ике атна дәвамында гакыйдә, фикһ, әхлак буенча гыйлем бирелде. Коръән аятьләрен өйрәтү, гарәп теле белән таныштырудан тыш балалар өчен кул эшләре, аш-су дәресләре дә үткәрелде.

Ниятләгәч, күңел иткәч, кризисы да, башка кыенлыклары да киртә була алмый икән ул. Киләчәкне кайгыртып кылган игелекле гамәлләрегез өчен Аллаһының ризалыгына ирешү насыйп булса иде.

### “Милләт” җәйләвендә 70 бала ял итте

Болгарда “Милләт” яшьләр үзәге, “Ярдәм” Ислам милли хәйрия фонды һәм Татарстанның Спас районы хакимияте тарафыннан оештырылган “Милләт” балаларны укыту-сәламәтләндерү җәйләвендә Татарстаннан һәм Россия төбәкләреннән 70 бала җыелды. Алар бергә сәләтләрен үстерү, талантларын ачу, татар телен һәм мәдәниятен өйрәнү, шулай ук археология серләре белән танышу максатыннан килде. Бу җәйләүнең бер үзенчәлеге шуннан гыйбарәт - бергә хәйрия максатыннан аз керемле, күп балалы гаиләләрнең сабыйларын кабул итәләр.

Җәйләүнең ачылу тантанасында Спас районы хакимияте башлыгы Камил Нугаев, “Ярдәм” фонды советы рәисе Илдар Баязитов, филология фәннәре докторы, профессор Хатыйп Миңнегулов, “Милләт” яшьләр үзәге җитәкчесе Александр Долгов, археолог Айрат Гобәйдуллин, шагыйрә Лилия Сәлахова, Франция журналисты Жанна Баяр, тарих фәннәре кандидаты, лагерь директоры Динар Шәмсетдинов һәм башкалар бар иде. Тантанада катнашкан кешеләр балаларга актив ял һәм ныклы дуслык, уңдырышлы эш теләделәр. Ә Жанна Баяр махсус бу очрак өчен татар телендә җыр өйрәнгән һәм ул аны җәйләүнең ачылышында җырлап та күрсәтте.

### Мөселман балалары чит илдә дә ял итә

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан Төркия дини эшләр идарәсе белән берлектә Истамбулда балалар өчен Коръән һәм төрек телен өйрәнү курсы оештырылды. Мәчетләр каршындагы укуларга йөргән, төрле дини чараларда, конкурсларда катнашкан 18 малай һәм 18 кыз ай дәвамында Истамбулда белем алачак. Алар өчен төшке ашка кадәр дәресләр үткәрелә, аннары мәдәни чаралар, мәчетләргә экскурсияләр оештырыла. Балалар республиканың төрле районнарыннан җыелган.

# Кемнең бәлеше тәмлерәк?



**Түбән Кама районының Ташлык авылыннан бик тә үзенчәлекле бәйге турындагы хәбәр килеп иреште. Анда әбиләр арасында бәлеш конкурсы узган.**

Ураза бәйрәме көнендә була бу. Гает намазыннан мәчеттән чыккан ирләр башта тәмле пылау белән сыйланалар. Ә кичен әбиләр бәйрәм кичәсенә коймак-бәлешләр пешереп алып киләләр. Муллалардан торган махсус комиссия бәлешләргә бәя бирә (рәсемгә күз салыгыз), җиңүчеләр – ә монда әбиләрнең барысы да, һичшиксез, җиңүче инде - истәлекле бүләкләр белән сөендерелә. Вәгазьләр тыңлап, балаларның чыгышларын карап, бергәләп догалар кылгач, күңелләр хозурлана. Балаларга да иганәчеләр ярдәме белән әзерләнгән бәйрәм күчтәнәчләре тапшырыла.

# “Килен белән каенана”



**Өлкән яшьтәге мөселман кардәшләребез дә җәйләрен заяга уздырмаска тырышканнар.**

Бөгелмә мөхтәсибәтенең “Нурия” мөслимәләр клубы, мәсәлән, “Килен белән каенана” дип аталган чара үткәргән. Әлеге чара яшьләрне дингә тарту, киленнәргә каенаналары белән уртак тел табарга ярдәм итү максатыннан оештырылган. Кунаклар Лениногорск, Казан, Чирмешән, Самара шәһәрләреннән дә килгән. Чарага махсус чакырылган киленнәр һәм каенаналар исә махсус биремнәрне үтәп күрсәткәннәр: алар бер-берсе хакында сөйләгәннәр, бергәләп чәчәк гөлләмәсе ясаганнар, ислам турындагы сорауларга җавап биргәннәр. Ахырдан исә барлык катнашучылар, кунаклар чәй табыны артына җыелган.

***Ә сезнең мәхәлләдә нинди яңалыклар бар? Хәбәрләрегезне naubahar67@list.ru адресы буенча редакция почтасына юллагыз.***

# Алман илендәге мөселманнар тормышы




**Вәсилә РӘХИМОВА,**
**КАЗАН-МЮНХЕН-КАЗАН**

Рамазанның соңгы көнендә, 16 июльдә аяк бастык без Европа уртасындагы ерак алман җиренә. Очкычыбыз Мюнхен каласына әйбәт кенә китереп җиткерүгә, Баварияга, күпгасырлык тарихлы, кайчандыр герцоглар шәһәре саналган Айһаһ каласына юл тоттык. Җәй уртасы, кай якка карама – хозурлык: тук башаклы иген кырлары, геометрик төгәллек белән бүленгән яшелчә, җиләк-җимеш бакчалары, уңышы өлгереп җиткән кукуруз, бәрәңге басулары озата бара.

Ул да түгел, мул уңыштан сыгылып торган җыйнак кына бакча-кырлар янәшәсендәге олы юл өстендә затлы чәчәкләр плантациясе сәламли безне. Машинаңны туктатып, рәхим итеп, үзеңә ошаганын кисеп ал да, тиешле сумманы үзең белеп, кассага калдыр...

Уңган, тырыш фермерлар кишәрлекләрендәге үзләре җыеп өлгермәгән чия, слива, кура җиләге, эре-эре күк җиләк ише нигъмәтләрне килеп җыйсын өчен халыкка бөтен уңайлыкларны булдырган: озын баскычлар, утырып ял итәр өчен өстәл-урындыклар, хәтта балаларга уен мәйданчыкларына кадәр куелган. Җиләк-җимештән авыз ит, көнозын сыйлан, сүз әйтүче юк, елмаеп сәламләшәләр дә, һәркем үз юлында. Ә өйгә алып кайтырга дип җыйганны кибетләренә кереп үлчәтеп, тиешле хакны калдырасың. Алыш-биреш тә үзара ышанычка, намуска корылган. Фермер хуҗалыгы нәрсә үстерә – барысы да кибет киштәсендә...

Сәгать ярымлык юлны узганда, күпме мәгълүмат алып, тәэсирләнеп, менә, ниһаять, Айһаһка аяк бастык. Шәһәрдә яшәгән 21 мең кешенең якынча 3 меңе мөселман, диделәр. Күпчелеге төрекләр, гарәп илләреннән күчеп килгән сары, кара тәнле халыклар. Шәһәр үзәгендә Германиянең Кёльн шәһәрендә урнашкан төрек мөселман җәмгыятенә караган ике гыйбадәт йорты бар. Без килгән "Фатин" мәчетенең (манарасы булмаса да, урамдагы күрсәткеч тактасында мәчет дип язылган) 25 еллык тарихы бар. Мөселманнар сафы үсә барганлыктан, мәхәллә җитәкчелеге киләчәктә киңәю, янәшәдән тагын бер бина алу нияте белән йөри.

"Фатин" бөтен уңайлыклары булган 3 катлы йортта урнашкан. Беренче катта ашханә, ял итү, аралашу, дәрес алу бүлмәсе. Икенче катның бер ягында имамның яшәү урыны, каршы якта – фарыз залы. Ә өченче кат тулысы белән хатын-кызлар карамагында: монда да ашханә, тәһарәтханә, дәрес алу һәм намаз залы. Шимбә-якшәмбеләрдә 2 төркем булып балалар дин сабагына килә. Укулар түләүле, чөнки мәхәлләне тоту өчен матди чыгымнар да, Төркиядән 3 ай саен имам чакыртып, аңа хезмәт хакы түләү дә мәхәлләгә йөрүчеләр кайгыртуында. Безнеңчә әйтсәк, мәхәлләдә әгъза булып торучылар ай саен тиешле взнос кертеп баралар, чыгымнар мөселманнар өстендә.

Рамазанның соңгы кичен мәчеткә ястү намазына дип атап, гаиләләре белән җыелышып килгән төрек хатыннары белән бергә уздырдык. Витр намазына керешкәнче, бирегә икешәр рәкагатьле 2 тәсбих намазы, аннан соң Коръән укып, озаклап дога кылып озаталар икән уразаны. Бу минутларда күпләр тәэсирләнде, күңелләр тулды, күзләр яшьләнде.

17 июль – Гает бәйрәме, җомга көнебез дә күңелләрне хушландырган тәэсоратларга мул булды. Төрек кардәшләребез Абдулла һәм Түләй Кайя гаиләсе, ерак араларны якын итеп килгән безләрне хөрмәт итеп, туган-тумачасы янына Гает чәенә дәште.

## БЕЗ ДӘ ХАКНЫҢ БӘНДӘСЕ...

Җомга намазыннан соң, якындагы Аугсбург шәһәренә төрек кибетенә хәләл иткә барып килдек. Алман иленең кечерәк кенә шәһәрләрендә дә "SELAM" маркасы астында хәләл ризык, хәләл иттән сыгылып торган супермаркетлар тота алулары төрек кардәшләргә карата булган хөрмәтемне икеләтә арттырды. Һәм мөселманнар өчен сөенеп туймадым. Мөселманча көн итүне, дин-исламыбыз таләпләренә туры килгәнчә яшәүне төрек кардәшләребез үз агымына җибәрмәгәннәр. Киресенчә, бөтен җаваплылыгы белән, юлларын табып, үз кулларында тоталар! Аларның төп ватаннарыннан еракта да динебез ислам кушканча яшәргә тырышулары, чыннан да, күпләр өчен өлге булырлык, соклангыч күренеш. Шуларны уйлый-уйлый, кичке бәйрәм табынына без дә яңа гына чалынган тана итеннән өчпочмак өлгерттек.

Гаетнең өченче көнендә өйлә намазыннан соң мәчеткә зур бәйрәмгә чакырдылар. Гаетне озатуга һәм алдагы мөбарәк айларны каршылауга багышланган иде ул. Имам хөтбә сөйләде, әлеге айларның хасиятләрен аңлатып, нәсихәтләрен җиткерде. Якшәмбегә туры килгәч, бу чарага халык агылды гына. Хатын-кызлар залы гадәттәгечә бала-чагага күмелде. Казаныбыз мәчетләрендә сабыйлары белән намазга килгән яшь әниләрне ачуланучы, бала тавышын сөймәүче әби-апаларны еш очратырга туры килгәнлектән, шул чак үзем дә сизмәстән: "Әһ" дип куйдым. Дингә тартыйк, гореф-гадәтләребезгә сабый чактан ук күндерик, диган халык баласын өйдә калдырмый шул, чыр-чуга да түземлек күрсәтә. Без дә хакның бәндәсе ләбаса...

## ТУПЛАУЧЫ, АРАЛАШТЫРУЧЫ МӘГЪЛҮМАТ КЫРЫ

Алман җирендә мәчетләр күплеген ишетеп белә идек. Мәхәлләләрнең белдерүләр тактасы – биредәге дин-ислам сулышының көзгесе: кайчан Коръән уку курслары оештырылачагы, корбан чалырга, хаҗ кылырга теләүчеләр игътибарына мәгълүматлар үзләре үк биредәге активлыкны әйтеп тора.

Кызыксына, сораша торгач, биредә безгә дә үрнәк булырлык тагын бер күркәм чарага нигез салынуын белдем. Ел саен июнь аенда мәчеттә "Ачык ишекләр көне" үткәреп, шәһәр халкын мәхәллә тормышы, ислам кыйммәтләре белән таныштыралар икән. Ислам дине белән кызыксынучыларга шулай ике көн буена экскурсия үткәрелә, төрек кардәшләр үзләре пешереп китергән ризыкларны саталар, урамда табын коралар. Ризык сатудан кергән акча мәчеткә тапшырыла. Шәһәр газетасында бу хакта алдан ук игълан бирелә. "Ачык ишекләр көне"ндә биргә шәһәр бургомистры килүе, төрле диннәр вәкилләре чакырылу ике як өчен дә күркәм аралашу, безнеңчә әйтсәк, җирле хакимият белән аңлашып яшәүне күрсәтә.

Кайсы мәчеткә, гыйбадәт йортына, мөселман товарлары, хәләл ризык сату кибетләренә барып кермә, Кёльнда урнашкан төрек ислам җәмгыяте үзәге Германиядә яшәүче дин кардәшләре өчен төрекчә чыгарган "Perspektef" журналына, "Milli gazette", "Camia" газеталарына тап буласың. Туган телендә мәгълүмат аласы килүчеләрнең динислам темасына кагылышлы ихтыяҗы шулай үтәлә. Дини бәйрәмнәргә, тегe яки бу чарага багышлап чыгарылган ике телдәге буклетлар, брошюралар да гадәти хәл. Немец телендәге Коръән тәфсире дә берничә тапкыр бастырып таратылган.

Кёльнда урнашкан үзәк төрек ислам җәмгыяте инсаннар арасында яхшылык, бербереңә ярдәмләшү, гаделлек кебек фундаменталь әһәмиятле принципларның үтәлүен кайгыртучы, аларны таратуга ярдәм итүче җәмгыять булып тора; Германиянең 34 районындагы 521 мәчет, 2282 ислам мәхәлләсенең эшчәнлеген урыннардагы җаваплы җәмгыятьләр аша координацияли. Кыскасы, мәхәлләләрдә динислам кушканча яшәүне оештыру кем ничек булдыра, шулай тарта дип түгел, үзәктән планлаштырылып, ярдәмләшеп алып барыла.

Рамазан гаете узу белән, биредәге мөселманнарның корбан аена хәзерлек башлауларына да, хаҗга җыенуларына да шаһит булдык. Мәхәлләдә яшьләр белән эшләү, алар арасында спорт ярышлары уздыру, белемнәрен тирәнәйтү өчен җаваплы Тамер улы Фуркан безгә бу хакта бәйнә-бәйнә сөйләде. Корбан чалырга теләүчеләр 100 евро акча китерәләр. Мәхәлләдә акча туплангач, араларыннан берничә вәкил ачлыкта, мохтаҗлыкта яшәүче Африка илләренә сәфәр чыгып, җыелган акчага анда корбаннар чалып, мөселманнарга бәйрәм шатлыгы өләшәләр икән. "Ел саен шулай. Сентябрь азагында үзем дә мөселман җәмгыяте үзәге кушуы буенча Чад иленә сәфәр чыгам. Бу игелекле эшне төрек мөселман җәмгыяте координацияли", – диде Фуркан кардәш.

Интернет челтәрендәге мәгълүматларга караганда, әле 1970 елларда гына Германиядә нибары 3 мәчет булган. Хәзер илдә барлыгы 350 меңнән артык мөселман исәпләнә һәм шуларның 117500е мәчет-мәхәллә әгъзасы булып тора. Кул сузымындагы якын тарихка күз салсак, төрекләр бу якларга эшче куллар сыйфатында икенче Бөтендөнья сугышыннан соң килә башлыйлар. Узган гасырның 60-70 нче елларында гаиләләре белән күпләп күчү башлана. Килеп урнашуга, җәмәгать булып оешып, намаз укый алырлык мәчетләр коралар. Еллар үтү белән берләшү ихтыяҗы, эшчәнлекне планлаштырып алып бару, бердәм координацияләү ихтыяҗы туа. Һәм 1995 елны милли ислам җәмгыяте үзәге оештырыла. Төп принцип – мөселманнарның иҗтимагый тормышта катнашуларын тәэмин итү, хокукларын һәм мәнфәгатьләрен кайгырту.

## ТУАРЫ БАРНЫҢ ҮЛЕМЕ ДӘ БАР

Әйе, тормыш булгач, гаилә дә корыла, балалар да туа, дәвалану да кирәк. Балага исем кушу, малайларны сөннәткә утырту, никах укытулар мөселманнар өчен бәхетле, кадерле вакыйгалар. Бу эшләрне алман илендәгеләр үз араларындагы белемле, хәзерлекле дин кардәшләреннән үтәтәләр. Минем белән әңгәмә корган, өч телдә теттереп аралашучы Хаҗәр һәм Исра ханымнар кечкенәдән Төркиядән күчеп килеп, биредә гаилә корган, насыйп ярларын тапкан яшьләр. Сөйләүләре буенча, чит диндәгеләр, башка халыклар арасында гомер итүнең кыенлыгын сизмиләр икән алар. Гаилә кору, егетләрне-кызларны башлы-күзле итү дә мәхәлләгә тупланып яшәгәч, җиңел чишелә. Таныштыру, өйләндерәсе улы булганга үз араларыннан кыз күрсәтү, буй җиткән кызга кияү эзләшү гадәти күренеш. Шуңарга да катнаш никахлар да сирәк. Күрше Аугсбург шәһәрендә хатын-кызлар табибәсе бар. Ә бәбиләр чак җиткәч, католик динендәгеләргә хезмәт күрсәтүче шәхси клиникага баралар, чөнки аларда да хатын-кызлар бары тик хатын-кыз табибка күренергә тиеш икән.

(Ахыры 13 биттә.)

# Чын хәләлгә акча җәл түгел

Ураза гаете көннәрендә Балтачның Хәләл индустриаль паркында үткәрелә торган традицион ярминкә елдан-ел киңрәк колач ала. Илнең төрле өлкәләреннән җыелган эшмәкәрләр быел да бирегә үзләре җитештергән хәләл продуктларны, милләтебез рухын чагылдырган күп төрле товарларны тәкъдим иттеләр.

Татарстан шәһәрләре һәм районнарыннан тыш Түбән Новгород, Киров, Мордва, Пенза, Мари Иленнән дә килгәннәр иде. Ярминкәне Хәләл индустриясенең милли ассоциациясе Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Диния нәзарәте каршында эшләп килүче “Хәләл” стандарты комитеты, Балтач муниципаль районы, “Балтач” хәләл индустриаль паркы ярдәме белән оештырды.

Ярминкә ярминкәдер инде, алар хәзер һәркайда уздырыла, диярсез сез. Алары гадәти ярминкә бит аның, ә менә Балтачта ел да хәләл ярминкә оештырыла. Моның өчен район үзәгенең иң матур болыны сайлап алына. Сатучылар өчен дә, алучылар өчен дә бөтен шартлар тудырыла. Ә хезмәт күрсәтүчеләре мөлаем елмаеп, үз товарларын алырга чакырып тора. Күзне кызыктырырлык итеп, әллә ничә төрле кабымлык тезеп куйганнар: ысланган тавыгы, казылыгы, сыры, балы... Казылыкның ничек эшләнүе турында төрле сүзләр ишетеп, бик күп тапшырулар карагач, инде аны күп еллардан бирле алганым юк иде. Ә биредә Самарадан килгән кардәшләребезнең хәләл казылыгын авыз иткәч, тәмлелекләренә исләрем китеп, акча янчыгымны чыгаруымны сизми дә калдым. Әле Казанга кайткач, дуслар, туганнар, күбрәк алмагансың шунда, дип шелтәләп тә алдылар үземне.

Менә чигүле камзул, түбәтәй кигән озын буйлы егет колач җәеп үз янына чакыра. Елмаешып күрешәбез, әйтерсең лә туганнар. Икмәк пешереп сата икән, ризыктан авыз итүебезне үтенә. Нинди тәмле, дибез, авызда үзгә икмәк тәмен тоеп.

– Бу икмәк борынгы рецепт буенча, камыр башыннан, чүпрәсез килеш пешерелә, - дип сөйләп китә Фәрит Заһидуллин. – 1 тонна он, 2 ел вакытым китте шушы дәрәҗәгә ирешү өчен. Беркайда да юк мондый ипи.



Фәрит туганның визиткасын алып, “Чүпрәсез икмәк пешерү остасы” дигән сүзләрне укыйбыз. Шунда ук икмәкнең составы язылган: арыш, бодай оны, чишмә суы, диңгез тозы, кориандр... Фәрит, заказлар да кабул итәм, кирәк булса, өегезгә үк китереп бирәм, ди. Бер төркем халык белән уратып алынган баш казыебыз - Балтачның имам-хатыйбы мөхтәрәм Җәлил хәзрәт Фазлыев та килде бу ипи лавкасына, кара ипи алып, 100 сумын сузды.

– Нишләп бик күп бирәсез, хәзрәт, диюебезгә: “Бу бәһасез нигъмәт, чын хәләлгә акча җәл түгел, – диде ул елмаеп.

Һәр сүзен ачык, төгәл итеп әйткәнгә, гамәлен ихластан башкарганга бөтен җирдә олылыйлар, яраталар хәзрәтне. Әле ярминкә ачылуга сөйләгән вәгазен дә, безнең заман дин әһеле бит бу, әлхәмдүлилләһ, дип тыңлап тордык.

– Бүгенге Ураза гаете бәйрәменә күп яклардан җыелган кардәшләрем, хәләл ярминкәгә килүегез өчен Аллаһның рәхмәте булсын, чөнки бу бәйрәм генә түгел, ә хәләл ризыкның тәмен тату, танышу, балаларыбызны хәләл белән тәрбияләп үстерүнең мөһимлеген төшендерү чарасы да. Киләчәгебез өчен, сау-сәламәт буын үстерү өчен хәләлнең заруриятен, аның төп яшәү тәртибе икәнлеген аңлау кирәк.

РТ Премьер-министры киңәшчесе Линар Якупов та шул фикерне куәтләде:

– Бәйрәмебезне 4 нче ел үткәрәбез. Әлхәмдүлилләһ, менә тагын җыелдык. Балтачлыларга зур рәхмәт. Бигрәк тә Җәлил хәзрәт Фазлыевка, аның халкыбызны иманга кайтаруда ару-талуны белми эшләве сокландыра. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенә, Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына, Балтач районы хакимиятенә зур рәхмәтләр. Динебез үсә, шөкер, хәләлне җитештерүчеләр көннән-көн күбәя. Ярминкә – актив сәүдә итү, яңа эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыру чарасы да ул.

Балтач районы башкарма комитеты башлыгы Рамил Шакировның да шатлыгын белдерер сүзләре күп иде:

– Кичә гыйбадәт йортларында изге догада булып, бәйрәм итсәк, бүгенге бу очрашуыбыз шуның дәвамы кебек. Бәйрәмебез, ярминкәбез мөбарәк булсын, кардәшләр. Илебезнең төрле төбәкләреннән хәләл ризыклар, көнкүреш товарлары алып килгәнсез, барчагызга зур рәхмәт.

Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм Хәйруллин, халыкны күркәм бәйрәм белән котлагач, болай дип өстәде:

– Мондагы бөтен ризык – хәләл, курыкмыйча ашагыз, күчтәнәчкә алыгыз. Хәләлне ашаган кеше таза-сау булыр, ә хәрамны ашаса чирләшкә булыр.

Чыгышлардан соң бик күп мөнәҗәтләр авторы, яраткан җырчыбыз Ильяс Халиков “Хәерле булсын гамәлең” дигән мәдәни сәгатьне ачып җибәрде. Аннары сәхнәгә “Казан егетләре” күтәрелде. Менә ичмасам безнең егетләр җырлап та куя, биеп тә күрсәтә! Матур, моңлы көйләребезне оста башкаруларына мөкиббән киткән халык рәхмәтләрен яудырды гына үзләренә. Балтач үзешчәннәре дә сокландырды. Әле бит анда Эквадор кунаклары да килгән иде. Ваукикуна (бертуганнар дигән сүз икән) – урам музыкантлары, җырчы-биюче коллектив. Костюмнары, җырлары-биюләре – шаккаткыч. Без аларны Бауман урамында кышын да, җәен дә күрәбез, ә менә авыл халкы өчен бу әкәмәт бер тамаша булды.

Ярминкә булгач ярминкә инде. Анда сәүдә кайнап тора, күңел ачу уеннары гөрли. Балалар мәйданчыгында чыр-чу, рәхәтләнәләр генә. Көне дә кызу иде, без Мари Иленнән килгән эшмәкәрләрнең өстәле янына кат-кат бардык ул көнне. Күпме барсаң да самавырлары кайнап тора, ә чәйләре... Үзебезгә дә, күчтәнәчкә дә җитәрлек итеп сатып алдык кырлыган (иван-чай) дигәннәрен. Безнең урман-кырлар әнә шундый файдалы үләннәргә гаҗәеп бай бит ул, – дип мактый-мактый сата товарын эшмәкәр Евгений Петров.

Бөгелмә кымызы өстәле янында да кеше өзелеп тормады ярминкәдә. Ә безгә сап-сары чәчләренә татар калфагы кадаган кыз, ягымлы елмаеп, бәләкәй стакан суза: “Талканнан да авыз итеп карагыз инде. Ифрат та файдалы, дару да кирәкми моны эчсәгез”, - ди. Монысы Башкортстан нигъмәте икән. Казандагы кибетләренең адресын да бирде сатучы кыз.

“Күчтәнәчкә Гарәп Әмирлекләреннән кайткан чәйне дә алып җибәрегез әле, апалар”, - дип елмая Данис Гафуров атлы егет. – Яшел чәй кирәкме, әллә лимон, ромашка кушып ясалганын биримме? Чәебез бик тәмле, халык яратып ала”. Татар чәйдән баш тартамы соң инде! Алдык, Данис чәйгә өстәп матур гына кружка да бүләк итте.

Бүләк дигәннән, мин үзем дә үземә матур бүләк ясадым бит әле ярминкәдә. Казаннан кардәшләребез бик матур көмеш бизәнү әйберләре алып килгәннәр икән. Бу хәтле хозурлыкны күреп, тыныч кына үтеп китә алмадым, Балтач истәлеге итеп, “Аллаһ” дип язылган көмеш йөзек сатып алдым. Аңа сөенүем! Әле хәзер дә карап туялмыйм.

– Менә сәхнәгә олы сумкасын күтәреп, Хәләл индустриясенең милли ассоциациясеннән килгән Флюра Абдуллина күтәрелде. Ильяс Халиков белән алар бергәләп кызыклы викторина уздырдылар. Сорауларга тиз һәм дөрес җавап бирүчегә – бүләк. Башта бәләкәчләр көч сынашты, аннары чират олыларга да җитте. Соңыннан ярминкәдә катнашучыларга дипломнар тапшырылды.

Хәләл ризыкның тәмен, Балтач данын танып да еракларга таратты бу ярминкә. Ә безнең күңелләрдә ел буена сагынып сөйләрлек якты бер хатирә калды.

**Мөслимә ШӘФЫЙК**

# Алман илендәге мөселманнар тормышы

**(Ахыры. Башы 12 биттә.)**

Ә менә үлем-китем булса, мөселман зираты юк икән әлегә. Европа илләрендәге мөселманнарны ватаннарында җирләүне оештыруны үз өстенә алган “УКБА” фирмасы ярдәменә исәп тоталар.

**КҮП ЙӨРГӘН – КҮП КҮРӘ**

Килгән-килгән, якын-тирәдәге мәчетләрне дә барып күрәсе иттек. Дунай елгасы буена урнашкан, 132 мең кеше яшәгән Ингольштадт шәһәрендәге Германиядә зурлыгы буенча өченче булган “Косатере” мәчетенә махсус бардык. 800 кешегә исәпләнгән, ике манаралы бу Аллаһ йорты 2008 елны ачылган. Биредә яшәүче мөселманнар көче белән, халыктан кергән акчага салынган, 5,5 млн еврога төшкән ул. Башка мәчетләр кебек аны да мәхәллә әгъзалары тота. Биредә ислам мәдәнияте үзәге, уку-укыту бүлеге, спортзал, хәләл ресторан урнашкан. Бавариядәге зурлыгы буенча Мюнхеннан соң икенче шәһәр саналган бу калада 6 меңнән артык мөселман яши һәм иман йортлары төзү ихтыяҗы да үсә бара.

#8 (241) август 2015/
шәүвәл – зөлкагдә – 1436

# Җеназа

КЕШЕ вафат булыр алдыннан, башын Кәгъбәтулла ягына каратып, аны уң ягына яткырырга кирәк. Әгәр нинди дә булса сәбәпләр аркасында болай эшләү мөмкин булмаса, йөзен һәм аякларын кыйблага каратып, башын күтәребрәк куялар. Алай да кыен булса, аңа ничек җайлы – шулай итеп яткырырга кирәк. Мәҗбүр итмичә, йомшак кына түбәндәге сүзләрне әйтергә ярдәм итү тиешле: **«Ләә иләһә илләллаһ, Мүхәммәдәр-расүлүллаһ»** *(«Аллаһы Тәгаләдән башка һичбер гыйбадәт кылырга лаеклы илаһ юктыр, Мөхәммәд Пәйгамбәр (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм) – Аллаһының илчеседер»)*. Әгәр ул әлеге сүзләрне әйтсә – аның белән сөйләшмәү хәерле, аның гомерендә изге сүзләр соңгысы булып калсын. Шулай ук «Йәсин» сүрәсен уку киңәш ителә.

Үлгән кешенең күзләрен йомдырырга, башын, авызы ачылмасын өчен, иягеннән баш түбәсенә бәйләп куярга, бөкләнгән булсалар – аяк-кулларын турайтырга кирәк. Мәетне, алгы ягы һәм аяклары белән кыйблага таба каратып, биегрәк урынга салалар, кул бармакларын бергә кушалар, кулларын як-якка сузып аякларын янәшә салалар; эче күпермәсен өчен аның өстенә тимер кайчы куярга тәкъдим ителә, тәнен үтә күренмәле булмаган җиңел тукыма белән капларга кирәк.

Үлгән кешене шул ук көндә күмү мөмкин булмаганда, берничә хатын-кыз төне буе мәет саклый, тәһлил әйтә, Коръән укый, вәгазь сөйли һәм кәфенлек әзерли.

Мәетне юганга кадәр аның янында Коръән-Кәрим аятьләре уку рөхсәт ителә. Үлгән кешенең бөтен туганнарына һәм якыннарына үлеме турында хәбәр итәргә, мәетне күмүгә хәзерлек эшен тизләтергә, әгәр дә бурычы калган булса, аның өстеннән җаваплылыкны төшерү өчен, тиз арада аны түләргә, шулай ук үлгән кешенең васыятьнамәсе булса, аны тапшыруны тизләтергә кирәк.

### МӘЕТНЕ ЮУ

Юу өчен мәетне хуш исле матдә белән эшкәртелгән махсус тагаракка (колашага) салалар, киемнәрен салдыралар һәм гаурәтен (кендегеннән алып тезләренә кадәр) тукыма кисәге белән каплыйлар.

Мәетне юганда түбәндәгеләрне үтәү тиешле:

⦿мәеткә бары тик кирәк булганда гына карарга;

⦿әгәр дә аның гәүдәсендә үзе исән вакытта яшереп килгән җитешсезлекләр ачыкланса – аны беркемгә дә әйтмәскә;

⦿мәетне аерым бүлмәдә – кеше күзеннән яшерен почмакта юарга;

⦿мәетнең гаурәтенә карарга, шулай ук аңа кул белән орынырга ярамый, шуңа күрә мәетне юганда дүрт мөселман әһеленә мәет өстендә тукыма кисәген тотып тору киңәш ителә;

⦿мәетнең гаурәт җирләрен юганда чүпрәк яисә шуңа охшаш бер нәрсә куллану вәҗиб (мәҗбүри) саналса, мәетнең башка җирләрен юганда исә – чүпрәк куллану тәкъдим ителә;

⦿мәет юа торган бүлмәдә булган барлык көзгеләрне ябарга кирәк, әгәр дә аларны каплау мөмкин булмаса – ул мәҗбүри түгел;

⦿мәетне юа торган су җылы булырга тиеш, суга сабын вә хуш исле әйберләр кушу рөхсәт ителә;

⦿мәет юганда ярдәмчеләр яисә билгеле бер кешеләр генә була.

Аннары мәетнең нәҗесе сөртелә (моның өчен мәетнең эчен җиңелчә генә сыпырырга, нәҗесне чыгару өчен арт юлын юганда суны күбрәк салырга, аннары корытырга кирәк), мәет юучы, үз кулын чүпрәк белән урап, мәетнең гаурәтен сабынлап юа (ягъни истинҗә кылдыра).

Шуннары, авызын һәм борынын чайкамыйча гына, тәһарәт (вүду) алдыралар, чөнки мәетнең борынына яисә авызына су керсә, ул эчкә эләгәчәк, шулай да юеш чүпрәк белән аның авыз-борынын аерым-аерым сөртеп алу тәкъдим ителә.

Аннары түбәндәге рәвештә мәет юуның беренче мәҗбүри гамәлләре башкарыла: сабын вә мунчала белән башын һәм сакалын әйбәтләп юалар, аннары, сабынны суга тидереп, тагын бер кат чиста су белән юалар. Аннан соң мәетнең башын, йомшак кына алга таба идереп, бармак белән авызын, тешләрен, борынын юалар (мәетнең эченә су керүдән сакланырга кирәк); тырнак асты чистартыла; шуннан соң мәетне сул ягына салып, сабын һәм мунчала белән баш очыннан алып аяк очларына кадәр уң ягы юыла, уң ягына салып, шулай ук сабын һәм мунчала белән, сул ягын юалар, әйләндергән саен мәет өстенә өч мәртәбә яисә аннан да күбрәк тапкыр су коялар.

Алга таба мәетне икенче һәм өченче тапкыр тулысынча юу башкарыла (мәндүб), так санда булса – әйбәтрәк була (өч яки биш, яисә җиде), бу вакытта тәһарәт (вүду) алдырылмый. Соңгы тапкыр мәетне чайкаганда суга камфара яисә шуңа охшашлы нәрсә салына.

Аннары мәетне утырталар һәм йомшак кына итеп эчен сыпыралар, әгәр нәҗес чыкса – бары тик нәҗесне юып алу гына да җитә.

Бу эш тәмамлангач, мәетне корытып сөртәләр, башы һәм сакалына хуш исле әйбер сөртелә (ләкин зәгъфран белән түгел), сәҗдә урыннары (маңгай, борын, ике кулы, ике тезе, ике аягы) – аларга хөрмәт йөзеннән – камфара белән каплана.

Мәетнең чәчләре таратылмый, тырнаклары (сынганнарыннан кала) киселми, башындагы чәче һәм сакалы алынмый (моның кирәге юк), бу эшләрне башкару мәкруһ-тәхрими гамәл булып тора.

### МӘЕТНЕ КӘФЕНЛӘҮ

Ирләр кәфене өч өлештән – изар, камис һәм лифафадан тора, шулай ук кайбер төбәкләрдә чалманы кулланалар. Изар һәм лифафа – кеше буеның башы ягыннан да, аягы ягыннан да утызар сантиметр озынрак материя кисәкләре. Камис – муеныннан алып үкчәсенә кадәр ике озынлыктагы материя. Камисның уртасы Т хәрефе сыман кисеп куела. Өч кат кәфенләү мөмкинлеге булмаса, изар һәм лифафа белән генә чикләнү дә җитә. Сәбәпсез көе ике кат кына чорналса – мәкруһ – гөнаһлы гамәл булыр.

Кәфен аша мәетнең тәне күренмәсен, ул кәфенсез кебек булмасын. Кәфен чиста булуы шарт.

Кәфен өлешләрен түбәндәге тәртиптә җәеп куялар. Башта лифафа җәелә, аның өстенә изар, ә аннары – камис куела. Юылган мәетне башын камисның Т рәвешле кисеменә туры китереп салалар, башын кигезәләр һәм камисның калган өлеше белән үкчәсенә кадәр каплыйлар. Шуннан соң изар һәм лифафага урыйлар. Ураганда һәрвакыт уң яктан башлыйлар. Кәфенлек сүтелмәсен өчен, аны баш очыннан, аяк табаныннан һәм уртадан бәйләп куялар.

Хатын-кыз кәфенлеге биш өлештән: дирга (бөркәнчек), изар, лифафа, хымар (ахирәт күлмәге) һәм хиркадан тора. Дирга ирләрнең камис дип аталган өлеше кебек. Хымар дигәне – өч терсәк буе материя. Хирка – күкрәгеннән ботына кадәрле материя кисәге. Хатын-кыз кәфенен ирләрнеке сыман җәяләр. Юылган мәетне диргага салалар, башын Т сыман кисемгә кидерәләр, дирганың калган өлеше белән гәүдәне муеннан алып үкчәсенә кадәр каплыйлар. Шуннан соң чәчләрен ике толым итеп үрәләр, күкрәгенә салалар, хырка белән каплыйлар. Шуннан соң чәчләрен хымар белән каплыйлар, аннары изар һәм лифафа белән чорныйлар. Шулай ук, чишелмәсен өчен, өч урыннан бәйләп куярга мөмкин.

Кәфенләү алдыннан аны (ирләрнекен дә, хатын-кызныкын да) хуш исле әйбер белән эшкәртәләр.

Мәетнең чәчен алмыйлар, тырнагын кисмиләр.

Кәфенләгәннән соң, мәетне өйдән алып чыгу алдыннан, дога кылу өчен имамга һәм туганнарына аның янәшәсенә утырышырга кирәк. Аннары имам кыскача вәгазь сөйли, вафат булучыга дога кылу кагыйдәләре турында нәсыйхәт бирә. Гореф-гадәт буенча, барысы да күмәкләшеп эчтән генә йөз тапкыр тәһлил (Ләә иләһә илләл-лаһу) әйтә, аннары имам кыска сүрә яки аятьләр укый һәм үлгән кеше хакына кычкырып дога кыла.

### ҖЕНАЗА НАМАЗЫ

Җеназа намазы мөселман җәмәгатенең бурычы (фарыз кифая) булып тора. Җеназа намазын мөфти, яки казый, яки мөхтәсиб, яки имам укый. Бу кешеләрнең укырга мөмкинлеге булмаганда – имам рөхсәт иткән кеше укый. Җеназа намазын укыганда мәрхүмнең: «Фәлән кеше укыса иде», – дигән васыяте исәпкә алынмый. (Имам булганда башка кешенең (хәтта васыять буенча булса да!), мөхтәсиб булганда – имамның, казый булганда – мөхтәсибнең, мөфти булганда – казыйның, әмир булганда – мөфтинең җеназа намазы укуы дөрес булмый.)

Намаз түбәндәге тәртиптә башкарыла: мәетне җәмәгать алдына башын уңга каратып, Кәгъбәтуллаһка перпендикуляр рәвештә яткыралар. Имам мәетнең күкрәге турысына баса, калган мөселманнар аның артында рәтләргә тезелә, әлеге рәтләрнең бердән артыграк – өч, биш яисә җиде рәт булуы шарт. Җеназа намазын кайтарып уку мөмкин булмаганлыктан, аңа тәяммүм белән басу да рөхсәт ителә. (Мәетнең Аллаһы каршында дәрәҗәсе озатучылар саны белән түгел, җеназа намазында катнашучылар саны белән бәяләнә.) Җеназа намазы укуны башлау турында кычкырып әйтелә. Имам, кулларын күтәреп, беренче тәкбирне әйтә һәм аннары «Сәнә» догасын укый:

**«Субхәәнәкәл-лааһүммә үә бихәмдикә үә тәбаарәкәс-мүкә үә тәгәәлә җәддүкә үә ләә иләәһә гайрүк».**

*Мәгънәсе: «Әй Аллаһы, Сиңа дан һәм мактау булсын. Синең исемең мөбарәк һәм дәрәҗәң олуг. Синнән башка бернинди илаһи зат юк».*

Аннан соң икенче тәкбирне әйтә һәм Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават чыга:

**«Әллааһүммә салли галәә Мүхәммәдин үә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибраһиимә үә галәә әәли Ибраһиимә иннәкә хәмиидүм-мәҗиид. Әллааһүммә бәәрик галәә Мүхәммәдин үә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибраһиимә үә галәә әәли Ибраһиимә иннәкә хәмиидүм-мәҗиид».**

*Мәгънәсе: «Йә Рабби, Ибраһим галәйһиссәламгә һәм аның гаиләсенә рәхмәтеңне биргән кебек, Мөхәммәд галәйһиссәламгә һәм аның гаиләсенә дә рәхмәтеңне бир. Дөреслектә, Син – мактаулы һәм олуг зат. Йә Рабби, Ибраһим галәйһиссәламгә һәм аның гаиләсенә бәрәкәтеңне биргән кебек, Мөхәммәд галәйһиссәламгә һәм аның гаиләсенә дә бәрәкәтеңне бир. Дөреслектә, Син – мактаулы һәм олуг зат».*

Шуннан соң имам өченче тәкбирне әйтә һәм мәеткә дога кыла. Әгәр дә мәет ир кеше булса, түбәндәге дога укыла (түбәндәге догалар татарча да укыла ала):

**«Әллааһүммә-гъфир ли-**



**хәййинәә үә мәййитинәә үә шәәһидинәә үә гаа'ибинә үә сагииринәә үә кәбииринәә үә зәкәринәә үә үнсәәнәә. Әллааһүммә мән әхйәйтәһүү миннәә фә әхйиһии галәл-исләәми үә мән тәүәффәйтәһүү миннәә фәтәүәффәһүү галәл-иимән. Әллааһүммә ин кәәнә һәәзәлмәй'йиту мүхсинән фәзид фии ихсәәниһии үә ин кәәнә мүси'ән фәтәҗәәүәз гәнһ».**

*Мәгънәсе: «Йә Рабби, терeләребезне дә һәм үлгәннәребезне дә, монда булучыларны да һәм монда булмаучыларны да, кечкенәләребезне дә һәм олыларыбызны да, ирләребезне дә һәм хатыннарыбызны да ярлыка. Йә Рабби, тере булганнарыбызга ислам дине буенча яшәргә насыйп ит, ахирәткә китүчеләргә иман белән вафат булырга насыйп ит. Йә Рабби, әгәр ошбу мәет изге кеше булса – изгелеген арттыр, әгәр гөнаһлы кеше булса – гөнаһларын гафу кыл».*

Хатын-кыз булганда, түбәндәге дога укыла:

**«Әллааһүммә-гъфир лихәййинәә үә мәййитинәә үә шәәһидинәә үә гаа'ибинә үә сагииринәә үә кәбииринәә үә зәкәринәә үә үнсәәнәә. Әллааһүммә мән әхйәйтәһүү миннәә фә әхйиһии галәл-исләәми үә мән тәүәффәйтәһүү миннәә фәтәүәффәһүү галәл-иимән. Әллааһүммә ин кәәнәт мүхсинәтән фәзид фии ихсәәниһәә үә ин кәәнәт мүси'тән фәтәҗәәүәз гәнһәә».**

Баланы яисә акылга сай кешене җирләгәндә түбәндәге дога укыла:

**«Әллааһүммә-гъфир лихәййинәә үә мәййитинәә үә шәәһидинәә үә гаа'ибинә үә сагииринәә үә кәбииринәә үә зәкәринәә үә үнсәәнәә. Әллааһүммә мән әхйәйтәһүү миннәә фә әхйиһии галәл-исләәми үә мән тәүәффәйтәһүү миннәә фәтәүәффәһүү галәл-иимән.**

**Әллааһүммә-җгәл һәәзәл-мәййитә ләнәә фәртан.**

**Әллааһүммә-җгәлһү ләнәә әҗран үә зүхран.**

**Әллааһүммә-җгәлһү ләнәә шәфигән үә мүшәффәгә».**

*Мәгънәсе: «Йә Рабби, бу мәеткә безне җәннәттә каршы алучы булырга насыйп ит. Йә Аллаһы, бу мәетне безнең өчен шәфәгатьче кыл һәм шәфәгатеннән Үзең разый бул».*

Дүртенче тәкбирне әйтеп, имам сәламләүне тәмамлый.

Икенче, өченче һәм дүртенче тәкбирләрне әйткәндә куллар күтәрелми.

Җеназа намазын мәчет эчендә уку хупланмый.

## МӘЕТНЕ ҖИРЛӘҮ

Мәетне өйдән аягы белән алга каратып алып чыгалар, аннары гел башы белән алга табан алып баралар. Мәетне күтәреп баручылар алмашырга теләсә, алдан – уң яктан – башлыйлар. Сәгать теленә каршы юнәлештә алмашалар. Мәетне бары тик ирләр генә күтәреп бара. Мәетне тиз алып баралар, ләкин йөгермиләр, үлем турында уйлап барырга кирәк, дөнья мәшәкатьләре турында сөйләшергә, көлергә ярамый, шулай ук мәет алдыннан бару да тыела, бары тик аның артыннан гына барырга мөмкин; мәетне күмгәнче җиргә утырырга ярамый.

Кабернең тирәнлеге кеше буеның яртысыннан да ким булырга тиеш түгел; бераз тирәнрәк булса да ярый. Озынлыгы – мәет озынлыгы кадәр булырга, киңлеге – буеның яртысы кадәр булырга тиеш. Кабер кыйблага аркылы юнәлештә казыла. Кабернең иң астында кыйбла ягыннан ләхет алалар. Әгәр дә туфрак бик йомшак булса – ләхетне аста алсаң да ярый.

Ләхетне кабер уртасыннан алырга ярамый.

Мәетне ләхеткә куйганда түбәндәге доганы әйтәләр:

**«Бисмилләһ үә гәләә милләти рәсулилләһ».**

*Мәгънәсе: «Мәетне Аллаһы исеме белән һәм Мөхәммәд Пәйгамбәр милләтендә кабергә иңдерәбез».*

Ләхет эчендә мәетне уң ягына салалар, кәфеннең бәйләгән урыннарын чишәләр, ә ләхетне нинди дә булса материал белән ябалар. Болардан соң каберне күмәләр, бу вакытта имам Коръәннән («Та һа» сүрәсе, 55 нче аять) түбәндәге аятьне укый:

**«Минһә халакнәкум үә фиһә нөгийдөкүм үә минһә нухриджөкүм тәәратән ухраа».**

*Мәгънәсе: «Без сезне җирдән яралттык һәм үтереп янә җиргә кайтарабыз вә Кыямәт булганда икенче мәртәбә сезне җирдән чыгарабыз».*

Кабер өстенә цемент яисә гипс измәсе салу һәм фото кую тыела.

Мәетне җирләгәннән соң имам яисә ул вәкаләт биргән зат «әл-Мүлек (Патшалык)» сүрәсен укый һәм җирләнүчене ярлыкауны сорый. Аннары, дүрт мөселман кабернең дүрт читенә утырып, мәетнең башы янында «Әлиф, ләм, мим» («әл-Бәкара (Сыер)» сүрәсенең башы), ә аягы янында «Лилләһи» догасын укый. Әлеге догаларны белмәүчеләр берәр тапкыр «Фатихә» һәм унберәр тапкыр «Ихлас» сүрәләрен укый. Аннан соң имам укылган сүрәләрне мәрхүмгә багышлый. Шуннары, кабер янында имам гына кала, так санда тәхлил әйтә һәм мондый сүзләрне кабатлый *(исемнәре мисал буларак кына китерелә)*: *«Әй, Габдрахман Әхмәт улы (яки «Зөләйха Фатыйх кызы»), синең яныңа ике фәрештә килеп сорарлар: «Синең Ходаң кем?» – «Минем Ходам Аллаһы Тәгалә», – диярсең. Алар: «Синең пәйгамбәрең кем?» – дип сорар, син: «Минем пәйгамбәрем – Мөхәммәд Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм», – диярсең. Алар тагын: «Синең динең нинди?» – дип сорар, «Минем динем – ислам», – дип җавап бирерсең».*

Мөселман кешесен – мөселман зираты саналмаган зиратта, ә мөселман зиратында исә ислам динендә булмаган кешене җирләү тыела.

Җирләү вакытында зиратка хатын-кызлар кертелми.

Кабер ташының уртача биеклеге – җирлекнең уртача кар катлавының иң өске ноктасыннан – илле сантиметрдан да артык булырга тиеш түгел (Татарстан өчен кабер ташының биеклеге сиксән биш сантиметрдан туксан сантиметрга кадәр булырга мөмкин).

## ӨЧЕСЕ, ҖИДЕСЕ, КЫРЫГЫ КӨННӘРЕ ҺӘМ ЕЛЫ МӘҖЛЕСЛӘРЕ

Өчесе, җидесе, кырыгы көннәре һәм елы мәҗлесләрен үткәрү халык кабул иткән традиция булып тора. Әлеге мәҗлесләр түбәндәге тәртиптә үткәрелә.

Имам иң элек мәҗлескә килгән барлык кешеләрне дә сәламли, аннары утырып дога кыла:

**«Әллаһүммә әнзилнәә мөнзәлән мөбарәкән үа әнтә хайрул мөнзилиин».**

*Мәгънәсе: «Йә Аллаһы, безне бәрәкәтле җиргә төшерсәң иде, Син урнаштыручыларның иң хәерлесе» («Мөэминнәр» сүрәсе, 29 нчы аять).*

Аннан соң имам вәгазь сөйли, анда сүз, гадәттә, дөньяда кешенең вакытлыча гына булуы, гомернең бик тиз узуы хакында бара. Шулай ук, мәҗлестә катнашучыларга исламның төп төшенчәләрен җиткерергә мөмкин.

Вәгазь тәмамлангач, имам, мәҗлес кунаклары белән бергәләп, эченнән генә йөз тапкыр тәһлил әйтә. Аннары Коръән-Кәримнән сүрәләр укый. Гадәттә «Йәсин» яисә «әл-Мүлек (Патшалык)» сүрәсе укыла, ә кайчакта имам алар урынына берничә кыска сүрә, мәсәлән – «Фатихә», өч тапкыр «Ихлас», «Фәләкъ (Таң)» һәм «Нәс (Кешеләр)» сүрәләрен укый. Алардан соң дога кылына, анда мәҗлес хуҗасының вафат булган туганнарының исемнәре санап чыгыла һәм мәҗлес багышланган кешенең исеме *(яисә мәҗлес үткәрүчеләр искә алырга теләгән кешеләрнең исемнәре)* атала.

Аннары мәҗлестә катнашучылар сәдака бирә һәм имам дога кыла:

**«Әллааһүммә-хфәз сахибә һәзиһис-садәкати ганилаафәәти үәл-бәлиййәәти үәгъфир зүнүүбәһүү үә әккид иимәәнәһүү үә әксир әмүәәләһүү үә үәффикһү галәә хайри мәкасыйдиһ».**

*Мәгънәсе: «Йә Рабби, ошбу сәдака бирүчене афәтләрдән һәм бәлаләрдән сакла һәм шулай ук аның гөнаһларын гафу ит. Аның иманын куәтлә, малын арттыр һәм аңа хәерле максатларына ирешергә насыйп ит».*

Һәр табында сәдака өләшенә.

Сәдака таратуның тәртибе түбәндәгечә. Иң әүвәл йорт хуҗасы өләшә һәм аңа дога кылына. Башкалар акча өләшергә теләсә, ул уртага (тастымалга, тәлинкәгә һ. б.) салына һәм, имам дога кылганнан соң, мәчеткә яисә берәр мохтаҗ кешегә тапшырыла.

Ашаганнан соң имам, мәҗлестә катнашучылар белән бергәләп, тиешле доганы укый. Чисталыкны саклау максатыннан, мәҗлес башланганчы ризык куелган өстәлне каплап куярга да мөмкин, ләкин моны эшләү мәҗбүри түгел.

## ЗИЯРӘТ КЫЛУ

Зиратка кергәндә, мәрхүмнәрне искә алып, түбәндәге доганы укыйлар:

**«Әссәләмү галәйкүм әһледдияр минәл мөэмининә үәл мөслиминә үә иннә иншәә Аллаһү бикүм ләхикүүн әнтүм ләнәә фәратун үә нәхнү ләкүм тәбагүн нәсәлүЛлаһал гафия ләнәә вә ләкүм».**

*Мәгънәсе: «Әй, бу йортларның әһелләре! Сезгә Аллаһы Тәгаләнең сәламе булсын. АллаһыТәгалә дөньядан үткәннәргә вә сездән калганнарга да рәхмәт кылсын. Сез – бездән әүвәлге кешеләрсез, без – сездән соң калган кешеләрбез. ИншАллаһ, әлбәттә, сезгә кушылырбыз...».*

Зиратта Коръән сүрәләре укырга һәм үлгәннәргә дога кылырга кирәк. Гадәттә, анда «әл-Мүлек (Патшалык)» сүрәсе укыла.

Кабер янында булганда исерткеч эчемлекләр куллану, шәмнәр, веноклар, ясалма чәчәкләр кую рөхсәт ителми.

Шулай ук, кабер өстенә ятарга яисә аның өстенә утырырга һәм аңа басарга ярамый.

Үзеңнең берәр туганыңны эзләү максаты белән каберләр арасында йөрергә мөмкин, ләкин бары тик кабер ташларын уку өчен генә каберләр арасында йөрү хупланмый.

Зиратта кече һәм олы йомышны үтәү рөхсәт ителми.


**"Хозур" нәшрият йортында басылып чыккан "Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында НИГЕЗЛӘМӘ" китабыннан алынды**

## “Хозур” нәшрият йортының яңа кибете ачылды



**“ХОЗУР”** нәшрият йортының яңа кибете эшли башлады. Биредә “Хозур” чыгарган һәм башка нәшриятлар бастырган динебезгә, мөселманнар тормышына кагылышлы күп сандагы китаплар тәкъдим ителә. Яңа кибет Казанның Тукай урамында, 3нче йортта урнашкан. Белешмәләр өчен телефон: ***8 (843) 202 07 74. E-mail: huzur.inform@mail.ru.***

## “Хозур” яңа китаплар тәкъдим итә



“Хозур” нәшрият йорты “Дингә өндәү нигезләре һәм имам вазыйфалары” дип аталган дәреслек нәшер итте. Дәреслекнең авторы – РИИ мөгаллиме, тарих фәннәре кандидаты, Әниләр мәчете имам-хатыйбы Рамил (Габдулла) Әдһәмов.

***



“Хозур” нәшрият йортында Коръән фәннәре докторы Нуреддин Гитрның гарәп телендә “Коръән фәннәре” дәреслеге басылып чыкты. Тиздән нәшрият йортында аның татар һәм рус телләренә тәрҗемәләре дә дөнья күрер дип көтелә.




## КАЗАН ӨЧЕН СЕНТЯБРЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Таң беленә | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.09.2015 | 02:20 | 03:16 | 04:46 | 12:00 | 16:24 | 18:38 | 20:33 |
| 02.09.2015 | 02:23 | 03:18 | 04:48 | 12:00 | 16:22 | 18:36 | 20:30 |
| 03.09.2015 | 02:27 | 03:20 | 04:50 | 12:00 | 16:20 | 18:33 | 20:27 |
| 04.09.2015 | 02:30 | 03:22 | 04:52 | 12:00 | 16:18 | 18:31 | 20:23 |
| 05.09.2015 | 02:33 | 03:24 | 04:54 | 12:00 | 16:16 | 18:28 | 20:20 |
| 06.09.2015 | 02:36 | 03:26 | 04:56 | 12:00 | 16:14 | 18:26 | 20:17 |
| 07.09.2015 | 02:39 | 03:28 | 04:58 | 12:00 | 16:12 | 18:23 | 20:13 |
| 08.09.2015 | 02:42 | 03:30 | 05:00 | 12:00 | 16:10 | 18:20 | 20:10 |
| 09.09.2015 | 02:45 | 03:32 | 05:02 | 12:00 | 16:08 | 18:18 | 20:07 |
| 10.09.2015 | 02:48 | 03:34 | 05:04 | 12:00 | 16:06 | 18:15 | 20:04 |
| 11.09.2015 | 02:50 | 03:36 | 05:06 | 12:00 | 16:04 | 18:13 | 20:01 |
| 12.09.2015 | 02:53 | 03:38 | 05:08 | 12:00 | 16:01 | 18:10 | 19:57 |
| 13.09.2015 | 02:56 | 03:40 | 05:10 | 12:00 | 15:59 | 18:07 | 19:54 |
| 14.09.2015 | 02:59 | 03:42 | 05:12 | 12:00 | 15:57 | 18:05 | 19:51 |
| 15.09.2015 | 03:01 | 03:44 | 05:14 | 12:00 | 15:55 | 18:02 | 19:48 |
| 16.09.2015 | 03:04 | 03:45 | 05:15 | 12:00 | 15:53 | 17:59 | 19:45 |
| 17.09.2015 | 03:07 | 03:47 | 05:17 | 12:00 | 15:51 | 17:57 | 19:42 |
| 18.09.2015 | 03:09 | 03:49 | 05:19 | 12:00 | 15:48 | 17:54 | 19:39 |
| 19.09.2015 | 03:12 | 03:51 | 05:21 | 12:00 | 15:46 | 17:51 | 19:36 |
| 20.09.2015 | 03:14 | 03:53 | 05:23 | 12:00 | 15:44 | 17:49 | 19:33 |
| 21.09.2015 | 03:17 | 03:55 | 05:25 | 12:00 | 15:42 | 17:46 | 19:30 |
| 22.09.2015 | 03:19 | 03:57 | 05:27 | 12:00 | 15:40 | 17:44 | 19:27 |
| 23.09.2015 | 03:21 | 03:59 | 05:29 | 12:00 | 15:37 | 17:41 | 19:24 |
| 24.09.2015 | 03:24 | 04:01 | 05:31 | 12:00 | 15:35 | 17:38 | 19:21 |
| 25.09.2015 | 03:26 | 04:03 | 05:33 | 12:00 | 15:33 | 17:36 | 19:18 |
| 26.09.2015 | 03:29 | 04:05 | 05:35 | 12:00 | 15:31 | 17:33 | 19:15 |
| 27.09.2015 | 03:31 | 04:07 | 05:37 | 12:00 | 15:28 | 17:30 | 19:13 |
| 28.09.2015 | 03:33 | 04:09 | 05:39 | 12:00 | 15:26 | 17:28 | 19:10 |
| 29.09.2015 | 03:35 | 04:11 | 05:41 | 12:00 | 15:24 | 17:25 | 19:07 |
| 30.09.2015 | 03:38 | 04:13 | 05:43 | 12:00 | 15:22 | 17:23 | 19:04 |




ДИН вә Мәгыйшәт

Август саны, №8 (241)

**Мөхәррир:** Нәүбәһар КӘБИРОВА
**Дизайнер:** Гүзәл МИҢНУЛЛИНА

**РЕДАКЦИЯНЕҢ ҺӘМ НӘШЕР ИТҮЧЕНЕҢ АДРЕСЫ:**
420021, Казан шәһәре, Сафьян урамы, 8 нче йорт
**Электрон адрес:** naubahar67@list.ru
**Телефон:** +7 950 326 38 36

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН**
«Хузур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН**
ҖМДНнең дәгъвәт бүлеге житәкчесе **Нияз САБИРОВ;**
Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27).
**Нәшир:** «Хузур» нәшрият йорты (420021, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Сафьян урамы, 8 нче йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета **"Татмедиа" АҖ филиалы - "Идел-Пресс"** полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2).
**Тираж: 5 мең данә** Заказ **№ 9058**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - **6 сум.**
График буенча бу санга **24 нче август** көнне **20.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде.
Кул куелды: **20.00 сәгатьтә.**